# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР КОДЕКСЫ

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Җир турындагы законнарның төп башлангычлары

1. Татарстан Республикасының җир турындагы законнары җирләрдән нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны, туфракның уңдырышлылыгын торгызуны һәм арттыруны, табигать мохитен саклап калуны һәм яхшыртуны, җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның җиргә булган хокукларын яклауны тәэмин итү, дәүләт идарәсе юлы белән һәм җир кишәрлекләрен биләүчеләр инициативасы буенча җир кишәрлекләренең ирекле әйләнеше юлы белән хуҗалык итүнең төрле оештыру-хокукый рәвешләренең тигез хокуклы үсешен тәэмин итү максатларында җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салудан гыйбарәт.

2. Җир турындагы законнар түбәндәгеләргә нигезләнә:

а) табигать һәм хуҗалык объекты буларак, җирдән файдалануны җайга салуны бергә алып баруга;

б) җиргә милекчелек рәвешләренең күптөрлелегенә;

в) җир кишәрлекләренә карата үз хокукларын яклаганда җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның тигезлеген тануга;

г) гражданнарның һәм юридик затларның җирләрне биләүгә, алардан файдалануга һәм алар белән эш итүгә бәйле эшчәнлегенә

дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының законга каршы килерлек тыкшынуына юл куймауга;

д) җирләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенә.

3. Җирләрне биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китермәскә, гражданнарның һәм башка затларның закон белән сакланылучы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозмаска тиеш.

2 статья. Татарстан Республикасының җир турындагы законнары

1. Татарстан Республикасының җир турындагы законнары Татарстан Республикасы Конституциясенә, "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы эшләрне үзара бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында"гы Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнгән кысаларда Россия Федерациясе законнарына нигезләнә һәм әлеге Җир кодексыннан һәм Татарстан Республикасының аның нигезендә кабул ителүче законнарыннан һәм башка норматив-хокукый актларыннан гыйбарәт була.

2. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка законнарда булган хокук нормалары әлеге Кодекска туры килергә тиеш.

Әлеге Кодекс белән җир мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив-хокукый актлар арасында каршылык килеп чыккан очракта әлеге Кодекс гамәлдә була.

3. Җирләрне файдаланганда барлыкка килгән мөлкәти хокуклар граждани законнар һәм җир турындагы законнарның нормалары белән җайга салына.

4. Әгәр халыкара шартнамәдә әлеге Кодекстагыдан үзгәрәк кагыйдәләр билгеләнгән булса, бу чакта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

3 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләр

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләр - җир кишәрлекләреннән фай-

даланганда һәм аларны саклаганда барлыкка килүче мөнәсәбәтләр ул. Җир кишәрлекләре җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрнең объектлары булып торалар.

4 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының компетенциясе

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

1) җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) Татарстан Республикасының җир ресурсларына идарә итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләүче иң мөһим республика программаларын раслау;

3) Татарстан Республикасының административ-территория корылышы мәсьәләләрен хәл итү.

5 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясе

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) әлеге Кодекс һәм башка законнар нигезендә җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив-хокукый актлар кабул итү;

2) җирләрдән нәтиҗәле файдалану, туфракның уңдырышлылыгын арттыру, Татарстан Республикасының җир ресурсларын саклау буенча программаларны раслау;

3) махсус сакланылучы табигать территорияләренең һәм республика әһәмиятенә ия тарихи-мәдәни билгеләнешле җирләрнең чикләрен раслау;

4) җир кадастрын, җирләрнең мониторингын һәм җир эшләрен алып баруны оештыру;

5) җирләрдән файдалануны һәм аларны саклап калуны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны оештыру;

6) шәһәр торак пунктларының һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең җирләре чикләрен раслау;

7) җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү турында карарлар кабул итү;

8) әлеге Кодексның 59 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен бирү турында карар кабул итү;

9) республика буйсынуындагы район һәм шәһәр администрацияләре башлыклары карарларының һәм күрсәтмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм алар буйсынуындагы башка органнарның актларын юкка чыгару;

10) җир кишәрлекләрен дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алу турында карар кабул итү;

11) җиргә кагылышлы бәхәсләрне судка кадәр хәл итү;

12) шәһәр яны зоналарының чикләрен һәм режимнарын раслау;

13) әлеге Кодекс һәм башка законнар билгеләгән бүтән вәкаләтләрне тормышка ашыру.

<u>6 статья.</u> Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә халык депутатларының шәһәр һәм берләштерелгән Советы компетенциясе

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә халык депутатларының шәһәр һәм берләштерелгән Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр җирләре чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тәкъдимнәр кертү;

2) шәһәрдәге районнар җирләренең чикләрен билгеләү;

3) шәһәр төзелеше һәм табигатьне саклауның башка чаралары белән бер комплекста җирләрдән файдалану һәм аларны саклау программаларын раслау;

4) җир кишәрлекләрендә төзелеш кагыйдәләрен, аларны зоналаштыру кагыйдәләрен законнар нигезендә раслау;

5) үз ведомствосындагы территориядә җир турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору.

7 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә халык депутатларының район Советы компетенциясе

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә халык депутатларының район Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына район җирләре чикләрен үзгәртү һәм билгеләү турында тәкъдимнәр кертү;

2) җирләрдән файдалану һәм аларны саклау буенча район программаларын раслау;

3) район территориясендә җир турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору.

8 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә шәһәр администрациясе компетенциясе

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә шәһәр администрациясе компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) табигатьне саклау һәм шәһәр төзелешенең башка чаралары белән бер комплекста җирләрдән файдалану һәм аларны саклау буенча шәһәр программаларын төзү һәм үтәү;

2) әлеге Кодексның 59 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен бирү турында карар кабул итү;

3) әлеге Кодексның 115 статьясындагы "а","б","в","г" пунктларында каралган нигезләрдә җир кишәрлекләрен тартып алу;

4) җир кадастрын һәм җирләрнең мониторингын алып баруны оештыру;

5) җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тикшереп торуы;

6) үз компетенциясе чикләрендә җир турындагы бәхәсләрне судка кадәр хәл итү;

7) законнарда каралган тәртиптә җир кишәрлекләренә карата йөкләүләр билгеләү;

8) законнар нигезендә җир кишәрлекләрендә төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү һәм җир турындагы законнар бозылган очракта объектны төзүне яисә эксплуатацияләүне туктатып тору хакында карарлар кабул итү, экология-санитария һәм шәһәр төзе-

леше нормаларын кабул итү;

9) Татарстан Республикасы законнары нигезендә җир өчен түләү буенча өстенлекле ташламалар билгеләү;

10) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

9 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә район администрациясе компетенциясе

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә район администрациясе компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) әлеге Кодексның 59 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен бирү турында карарлар кабул итү;

2) әлеге Кодексның 115 статьясындагы "а","б","в","г" пунктларында каралган нигезләрдә җир кишәрлекләрен тартып алу;

3) җир кадастрын һәм җирләрнең мониторингын алып баруны оештыру;

4) җирләрдән файдалану һәм аларны саклау, туфракның уңдырышлылыгын арттыру буенча район программаларын әзерләү һәм үтәү;

5) җир төзү эшләрен алып баруны оештыру;

6) җир төзү эшләрен алып бару документларын әзерләүне һәм алып баруны оештыру;

7) авыл торак пунктлары җирләренең чикләрен билгеләү;

8) җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тикшереп торуы;

9) үз компетенциясе чикләрендә җир турындагы бәхәсләрне судка кадәр хәл итү;

10) җир кишәрлегенә карата законнарда каралган тәртиптә башка йөкләүләр билгеләү;

11) җир өчен түләү буенча Татарстан Республикасы законнары нигезендә өстенлекле ташламалар билгеләү.

10 статья. Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты һәм аның урыннардагы органнары компетенциясе

1. Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләр һәм Та-

тарстан Республикасы җир ресурсларыннан файдалану мәсьәләләрен дәүләт тарафыннан җайга салуны, тармакара координацияләүне гамәлгә ашыручы дәүләт идарәсенең республика органы булып тора. Үз компетенциясе нигезендә ул:

а) Татарстан Республикасы территориясендә җир ресурсларына идарә итү буенча тәкъдимнәр әзерли;

б) җир турындагы законнарны бозуларны бетерү турында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр җибәрә;

в) җир турындагы законнарны бозган өчен гаепле затларны җавапка тарту хакындагы мәсьәләләрне законда билгеләнгән тәртиптә карый;

г) предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм җир ресурсларын өйрәнүгә, алардан файдалануга бәйле җир эшләрен алып бару өчен һәм башка проект-тикшерү эшләре өчен рөхсәтләрне (лицензияләрне) гражданнарга бирә;

д) җир бәясе һәм аренда түләвенең нормативларын билгеләнгән тәртиптә раслауга тәкъдим итә;

е) җир кишәрлекләрен тартып алганда һәм биргәндә җир эшләрен алып бару экспертизасын үткәрә;

ж) җир төзү эшләрен алып баруны башкара, җирләрдән файдалануны һәм аны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны тормышка ашыра;

з) җир кадастрын һәм җирләрнең мониторингын алып бара;

и) гражданнарның һәм юридик затларның законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне яклау мәсьәләләре буенча судка мөрәҗәгать итә;

к) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган нигезләмә нигезендә башка мәсьәләләрне хәл итә.

2. Җир ресурслары һәм җир реформасы буенча район һәм шәһәр комитетлары Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитетының урыннардагы органнары булып торалар. Үз компетенциясе нигезендә алар:

а) җир турындагы законнарны бозуларны бетерү турында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр җибәрәләр;

б) предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм гражданнарның җир кишәрлекләренә карата хокукларын раслаучы документларны билгеләнгән тәртиптә бирәләр;

в) җир кишәрлекләрен тартып алу һәм бирү мәсьәләләрен ки-

лештерләр;

д) әлеге статьяның беренче пунктындагы "в", "ж", "з", "и" пунктчаларында каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

11 статья. Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре

Җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) үзләре милкендә булган җирләр белән эш итү;

2) җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны тикшереп тору;

3) законнарда каралган тәртиптә җир кишәрлекләренә йөкләүләр билгеләү;

4) үз компетенциясе чикләрендә җир турындагы бәхәсләрне судка кадәр хәл итү;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

2 бүлек. Татарстан Республикасы җирләре

12 статья. Татарстан Республикасы җирләренең составы

Татарстан Республикасында җирләр максатчыл билгеләнеше һәм хокукый режимы буенча түбәндәге категорияләргә бүленәләр:

а) авыл хуҗалыгы җирләре;

б) торак пунктлары җирләре;

в) сәнәгать, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, энергетика, оборона һәм махсус билгеләнешле җирләр;

г) махсус сакланылучы территорияләрнең җирләре;

д) урман фонды җирләре;

е) су фонды җирләре;

ж) запастагы җирләр.

13 статья. Җир кишәрлеге

1. Җир кишәрлеге - билгеләнгән чикләре, мәйданы, урнашкан урыны, хокукый статусы һәм җир кадастрында, җир кишәрлегенә

хокукларны дәүләт теркәве документларында чагылдырыла торган башка характеристикалары булган җирнең өске өлеше ул.

2. Җир кишәрлеге чикләре планнарда (сызымнарда) күрсәтелә һәм натурада билгеләнә.

3. Җир кишәрлегенең хокукый статусы максатчыл билгеләнешне, рөхсәт ителгән файдалануны һәм шушы җир кишәрлегенә карата билгеләнгән тәртиптә теркәлгән хокукны (милек, гомерлек мирас итеп биләү, даими (вакыты чикләнмичә), вакытын чикләп файдалану яисә арендалау хокукын) үз эченә ала.

4. Җир кишәрлекләре, шулай ук аларны башка җиргә күчерү билгеләнешләреннән артыграк чыгымнар таләп итәрлек һәм җир кишәрлекләренә бик нык бәйле булган объектлар (туфрак, йомык сулыклар, урман, күпьеллык агач-куаклар, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм башкалар) күчемсез мөлкәт була һәм, законда башкасы билгеләнмәгән булса, әйләнештә җир кишәрлеге белән бергә йөри.

5. Җир кишәрлеге бүленүле һәм бүленмәүле булырга мөмкин.

Максатчыл билгеләнешен һәм рөхсәт ителгән файдаланылышын үзгәртмичә генә өлешләргә бүленергә мөмкин булган, өлешләрнең һәркайсы максатчыл билгеләнешен һәм рөхсәт ителгән файдаланышын үзгәртмичә генә мөстәкыйль кишәрлек барлыкка китерүче яисә күләмнәре җир кишәрлекләре бирүнең әлеге Кодекста билгеләнгән минималь нормасыннан ким булмаска тиешле җир кишәрлеге бүленүчән дип танала.

Максатчыл хуҗалык билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдаланылышы буенча мөстәкыйль кишәрлекләргә бүленергә мөмкин булмаган кишәрлек бүленмәүчән дип танала.

6. Берничә гражданның яки юридик затның бүленмәүчән җир кишәрлегенә хокукы җир кадастры документларында натурада күрсәтелмичә генә беркетелә. Җир кишәрлегенең өлешө җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең өлешенә пропорциональ рәвештә йә яклар килешүе буенча яисә законнарда каралган башка шартларда билгеләнә.

<u>14 статья.</u> Гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре. Җир кишәрлегендә булу мөмкинлеге

1. Гражданнар дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә мил-

кендәге гомуми файдалану өчен ябык булмаган җир кишәрлекләрендә ирекле рәвештә, нинди дә булса рөхсәттән гайре генә булырга һәм бу кишәрлекләрдәге табигать объектларыннан законда һәм бүтән хокукый актларда, шулай ук тиешле җир кишәрлегенең милекчесе рөхсәт иткән чикләрдә файдаланырга хокуклы.

2. Әгәр җир кишәрлеге киртәләп алынмаган булса йә аның милекчесе кишәрлеккә керү урынын башка төрле ысул белән ачык итеп билгеләмәгән булса, теләсә кайсы зат милекчегә зыян китермичә яисә аны борчымыйча гына кишәрлек аша йөри ала.

15 статья. Максатчыл билгеләнеш һәм җирләрнең хокукый режимы

1. Җирләрнең максатчыл билгеләнеше - анык максатлар өчен җирләрнең категорияләренә туры килерлек итеп аларны эксплуатацияләүнең (файдалануның) законнарда билгеләнгән тәртибе, шартлары һәм чиге ул.

2. Җирнең хокукый режимы алардан файдалануның һәм граждани әйләнешкә, саклауга, исәпкә алуга һәм мониторингка кертү буенча җир, шәһәр төзелеше, урман, су турындагы табигатьне саклау законнары һәм җир асты байлыклары турындагы, мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау турындагы законнар белән билгеләнүче кагыйдәләрнең берлеге, ул билгеле бер категориягә кертелгән барлык җир кишәрлекләренә дә кагыла.

3. Берничә категориягә кертелгән җирләрдә тиешле категорияләр өчен урнаштырылган кагыйдәләр һәм чикләүләр гамәлдә булалар.

Җир кишәрлегенең хокукый статусы турында бәхәс чыкканда, катгыйрак хокукый режимлы җирләрнең категориясенә өстенлек бирелә.

4. Җирләр категорияләренең максатчыл билгеләнеше һәм хокукый режимы әлеге Кодекс һәм башка законнар нигезендә билгеләнә һәм шәһәр төзелеше, җир эшләрен алып бару документларында чагылдырыла.

16 статья. Җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану

1. Җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану - урнаштырылган

чикләүләрне һәм йөкләүләрне исәпкә алып, аңардан максатчыл билгеләнеше буенча файдалану ул.

Җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану җирләрне зоналаштыру нигезендә шәһәр төзелеше һәм җир эшләрен алып бару документлары белән билгеләнә.

2. Җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану түбәндәгеләргә карата таләпләрне үз эченә алырга мөмкин:

а) җирләрдән файдалану алымнарына һәм җирләрне деградацияләүгә, туфракның уңдырышлылыгын киметүгә яисә әйләнә-тирә табигать мохитен начарайтуга алып баручы алымнарны тыюга;

б) шәһәр төзелеше документлары һәм төзелеш нормалары, кагыйдәләре нигезендә төзелешнең тыгызлыгына, биеклегенә һәм тирәнлегенә;

в) тиешле зона яисә җир кишәрлеге чикләрендә социаль-мәдәни, коммуналь-көнкүреш, сәнәгать һәм башка төрле биналарны, корылмаларны һәм төзелмәләрне урнаштыруга;

г) кеше сәламәтлегенә тискәре йогынты ясарлык яисә аңа хәвеф-хәтәрне арттыру белән бәйле файдалану төрләренә;

д) әйләнә-тирә табигать мохитенә йөкләнешнең иң чик мөмкин нормаларына;

е) яшелләкләрне, археология ядкярләренең мәдәни катламын саклап калуга;

ж) законнар һәм башка норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән бүтән таләпләр.

3. Җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга кертелүче таләпләр исемлеге шушы җир кишәрлегенә булган хокукка карамастан билгеләнә.

4. Җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану җирләрне зоналаштырганда, шулай ук конкрет җир кишәрлекләрен биргәндә Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә һәм түбәндәгеләрдә күрсәтелә:

а) җир кишәрлеген бирү (тапшыру) турындагы карарларда;

б) дәүләт җир кадастры документларында;

в) сату-алу шартнамәләрендә һәм җир белән алыш-биреш итүләрне рәсмиләштерүче башка документларда;

г) дәүләт актларында һәм җиргә хокукны раслаучы башка документларда.

5. Җир кишәрлекләреннән рөхсәтле файдалануны үз ихтыяры

белән үзгәртүгә юл куелмый.

17 статья. Җирләрне категорияләргә кертү

1. Җирләрне категорияләргә кертү, бер категориядән икенчесенә күчерү Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

2. Җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерүнең бу Кодекста, башка законнарда урнаштырылган тәртибен бозу түбәндәгеләр өчен нигез булып тора:

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының һәм җирле үзидарә органнарының актларын, шулай ук җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләрне законнар нигезендә гамәлгә яраксыз дип таныр өчен;

җир кишәрлегенә хокукны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту.

3 бүлек. Авыл хуҗалыгы җирләре

18 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең төшенчәсе һәм составы

1. Авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү өчен һәм авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен файдаланылучы яисә шуның өчен билгеләнгән җирләр авыл хуҗалыгы җирләре дип танылa.

2. Авыл хуҗалыгы җирләре составында авыл хуҗалыгының уңдырышлы басу-кырлары һәм авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен кирәк булган хуҗалык эчендәге юллар, коммуникацияләр, йомык сулыклар һәм биналар, корылмалар, төзелмәләр һәм төзелешләр биләгән җирләр була.

3. Авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләренә сөрүлекләр, күпьеллык агач-куаклар биләгән җирләр, вакытлыча эшкәртүдән алынган җирләр, печәнлекләр һәм көтүлекләр керә.

4. Авыл хуҗалыгының уңдырышлы басу-кырлары аеруча саклanырга тиеш.

5. Авыл хуҗалыгы җитештерүе, крестьян (фермер) хуҗалыклары төзү һәм аларны киңәйтү, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнү өчен җирләрне яңадан бүлү максатларында җирләрне яңадан бүлү буенча дәүләт фонды булдырыла.

Күрсәтелгән фондны барлыкка китерү һәм аннан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

19 статья. Авыл хуҗалыгы җирләрен бирү

1. Авыл хуҗалыгы җирләре түбәндәгеләргә бирелә:

а) хуҗалык ширкәтләренә һәм җәмгыятьләренә, җитештерү кооперативларына һәм башка авыл хуҗалыгы оешмаларына - авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен;

б) дәүләт авыл хуҗалыгы оешмаларына (тәҗрибә-җитештерү, укыту, укыту-тәҗрибә һәм укыту-җитештерү хуҗалыкларына, фәнни-тикшеренү учреждениеләренә, югары һөнәр, урта һөнәр, башлангыч һөнәр авыл хуҗалыгы мәгариф учреждениеләренә һәм гомуми белем бирү учреждениеләренә) - авыл хуҗалыгы җитештерүе, фәнни тикшеренү һәм укыту максатлары өчен;

в) авыл хуҗалыгына карамаган оешмаларга, җәмәгать берләшмәләренә һәм дини оешмаларга - ярдәмче авыл хуҗалыгы алып бару өчен;

г) гражданнарга - крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару шәхси ярдәмче хуҗалык, күмәк һәм шәхси бакчачылык, терлекчелек, яшелчәчелек белән шөгыльләнү, печән чабу һәм көтү йөртү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән бәйле башка максатлар өчен.

2. Урманнар, куаклыклар, сазлыклар, карьерлар, авыл хуҗалыгы биналары, корылмалары һәм төзелмәләре биләгән җирләр законнарда билгеләнгән тәртиптә авыл хуҗалыгы оешмалары һәм предприятиеләре, крестьян (фермер) хуҗалыклары милкенә, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга, гомерлек мирас итеп билүгә, авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертү хокукы белән арендага бирелергә мөмкин.

4 бүлек. Торак пунктлар җирләре

20 статья. Торак пунктлары җирләре төшенчәсе һәм составы

1. Торак пунктлары җирләренә республика буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәр (шул исәптән район буйсынуындагы шәһәрләр) һәм

авыл торак пунктларын урнаштыру һәм үстерү өчен бирелгән җирләр кертелә.

2. Шәһәр һәм авыл җирләре составына түбәндәге җирләр кертелергә мөмкин:

а) торак һәм җәмәгать корылмалары - төзелгән һәм торак, мәдәни-көнкүреш, административ, гыйбадәт кылу һәм башка корылмалар һәм бината төзү өчен билгеләнгән җирләр;

б) гомуми кулланылыштагы - мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, юллар, елга буйлары, парклар, урман парклары, скверлар, бульварлар, сулыклар, кызыну урыннары һәм халык ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән башка объектлар биләгән җирләр;

в) сәнәгать корылмалары - сәнәгать, склад һәм башка җитештерү объектлары биләгән җирләр;

г) транспорт, элемтә, инженерлык коммуникацияләре - тимер юл, автомобиль, елга, һава һәм торбаүткәргеч транспорт, инженерлык инфраструктурасы һәм элемтә корылмалары биләгән җирләр;

д) табигать-тыюлык, табигатьне саклау, сәламәтләндерү, рекреация һәм тарихи-мәдәни билгеләнешле - табигать ядкярләре, урманнар, табигать, милли һәм дендрология парклары, ботан бакчалары, тыюлыклар, ландшафтлы территорияләр, табигый дәвалау факторларына ия булган һәм халыкның оешкан ялы һәм туристлык өчен билгеләнгән һәм шуның өчен файдаланылучы җирләр, тарихи һәм мәдәни ядкярләр, истәлекле урыннары булган җирләр;

е) су объектлары, сусаклагыч зоналар, гидротехник һәм башка су хуҗалыклары корылмалары биләгән җирләр;

ж) авыл хуҗалыгы файдалануындагы - сөрүлекләр, бакчалар, печәнлекләр, көтүлекләр биләгән җирләр;

з) резервтагы - шәһәр төзелеше эшчәнлегенә җәлеп ителмәгән җирләр һәм башкалар (торак пунктларының запас җирләре);

и) хәрби объектлар һәм режимлы зоналар.

<u>21 статья.</u> Торак пунктларының чик сызыгы

1. Торак пунктларының чик сызыгы - республика буйсынуындагы шәһәр җирләрен, шәһәр һәм авыл җирләрен башка категория җирләрдән аерып торучы тышкы чик ул.

2. Торак пунктларының чик сызыгын билгеләү шәһәр төзелеше һәм җир эшләрен алып бару буенча расланган документлар ниге-

зендә башкарыла.

Торак пунктларының чик сызыгы гражданнарның һәм юридик затларның җир кишәрлекләре чикләре буенча билгеләнергә тиеш.

3. Республика буйсынуындагы шәһәрләрнең һәм шәһәрләрнең чик сызыгы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Авыл торак пунктларының сызыгы район администрациясе тарафыннан раслана.

4. Җир кишәрлекләрен торак пункты җирләренең чик сызыгы эченә кертү бу кишәрлекләргә карата милекчелек хокукын, аларны биләү, алардан файдалану һәм аларны арендалау хокукын туктатуга китерми.

<u>22 статья.</u> Шәһәр яны зоналары

1. Шәһәр яны зоналары составына шәһәр чиге сызыгыннан читтә булган, шәһәр белән бердәм социаль, табигать һәм хуҗалык территориясен тәшкил итүче җирләр кертелә.

2. Шәһәр яны зоналарында шәһәр яны авыл хуҗалыгы җитештерүе, халыкның ял итү зоналары, шәһәр төзелеше һәм җир эшләрен алып бару буенча расланган документлар нигезендә һәм башка махсус таләпләргә (нормаларга, кагыйдәләргә, нормативларга) туры китереп, шәһәр үсеше өчен резерв җирләр территорияләре билгеләнә.

3. Шәһәр яны чикләре һәм режимы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Шәһәр яны зоналарындагы төзелеш өчен җир кишәрлекләрен бүлеп бирү турындагы карар шәһәр администрациясе белән килештерелергә тиеш.

## 5 бүлек. Сәнәгать, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, энергетика, оборона һәм башкалар өчен билгеләнгән җирләр

**23 статья.** Сәнәгать, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, энергетика һәм башкалар өчен билгеләнгән җирләр

1. Тиешле бурычларны үтәү өчен алдан билгеләнгән җирләр сәнәгать, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, энергетика һәм башкалар өчен билгеләнгән җирләр дип санала.

2. Файдалы казылмаларны эшкәртү өчен җирләр җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын тиешле тәртиптә рәсмиләштергәннән соң, җирләрне рекультивацияләү һәм аларның уңдырышлылыгын торгызу проектын раслаганнан соң бирелә.

3. Халыкның иминлеген тәэмин итү, сәнәгать, транспорт һәм башка төр объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында шулар чикләрендә җирләрне файдалануның махсус хокукый режимы кертелгән зоналар билгеләнә.

4. Сәнәгать, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, энергетика һәм башкага билгеләнгән җирләрдән файдалану кагыйдәләре, шулай ук махсус шартларда файдалану (саклау, санитария, яклау һәм башка) зоналары урнаштыру кагыйдәләре законнар нигезендә билгеләнә.

**24 статья.** Оборона һәм иминлек ихтыяҗлары өчен файдаланылучы җирләр

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби частьләре, хәрби мәгариф учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмалары, Россия Федерациясенең оборона һәм иминлек өлкәсендә законнарда билгеләгән бурычларын үтәүче башка министрлыклары һәм ведомстволарының гаскәрләрен урнаштыру өчен һәм аларның даими эшчәнлеге өчен бирелгән җирләр оборона һәм иминлек ихтыяҗларындагы җирләр дип таныла.

2. Оборона һәм иминлек ихтыяҗларына бәйле өйрәнүләр һәм башка чаралар үткәрү өчен җирләрдән вакытын чикләп файдаланыр-

га кирәк булганда, җир кишәрлекләре аларның милекчеләре, биләүчеләре, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар белән төзелгән шартнамәләр буенча файдаланыла.

3. Җирле администрацияләр һәм җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының, Россия Федерациясенең башка министрлыклары һәм ведомстволарының хәрби частьләре һәм предприятиеләре белән килешеп, законнар нигезендә оборона ихтыяҗлары өчен бирелгән җирләрдән юридик затларга һәм гражданнарга авыл хуҗалыгы файдалануга аерым җир кишәрлекләрен, урман җирләреннән тыш, вакыты билгеләнгән килеш биреп торырга хокуклы.

## 6 бүлек. Махсус сакланылучы территорияләрнең җирләре

25 статья. Табигать тыюлыклары фонды җирләре

1. Табигать тыюлыклары фонды җирләренә дәүләт табигать тыюлыклары (биосфера тыюлыкларын да кертеп) һәм заказниклар, милли парклар, табигать парклары, табигать ядкярләре, дендрология парклары һәм ботан бакчалары, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннар тереклек иткән һәм үсемлекләр үскән урыннар кертелә.

2. Табигать тыюлыклары фонды җирләре составына махсус экологик, фәнни, эстетик, мәдәни, рекреация һәм савыктыру әһәмиятенә ия объектлар һәм табигать комплекслары булган җир кишәрлекләре кертелә.

3. Дәүләт табигать тыюлыклары һәм заказниклар, милли парклар, табигать парклары, табигать ядкярләре, дендрология парклары һәм ботан бакчалары җирләрендә табигать комплексларын һәм объектларын саклап калуга һәм өйрәнүгә бәйле булмаган һәм Татарстан Республикасы законнарында каралмаган эшчәнлек тыела. Табигать тыюлыклары фондының башка җирләрендә алар өчен билгеләнгән режим нигезендә чикләнгән хуҗалык эшчәнлеге һәм рекреация эшчәнлеге рөхсәт ителә. Табигать тыюлыклары фонды җирләрен аларның максатчыл билгеләнешенә каршы килерлек ихтыяҗлар өчен тартып алу рөхсәт ителми. Табигатьне саклау фонды җирләренә бәйле эшләр законнар белән җайга салына.

4. Табигать парклары, милли парклар территорияләре составына табигать тыюлыклары фондына кермәгән башка категория җирләр дә керергә мөмкин. Әлеге җир кишәрлекләре аларның милекчеләреннән, биләүчеләреннән, алардан файдаланучылардан һәм аларны арендалаучылардан тартып алынмый һәм билгеләнгән режим нигезендә файдаланыла.

5. Дәүләт табигать тыюлыкларының һәм заказникларның, милли паркларның, табигать паркларының, табигать ядкярләренең, дендрология паркларының һәм ботан бакчаларының эшчәнлеге режимын тәэмин итү өчен саклау зоналары билгеләнергә мөмкин, бу зоналар чикләрендә махсус сакланылучы табигать территорияләрендә табигать комплексларына тискәре йогынты ясарлык теләсә нинди эшчәнлек тыела.

Саклау зонасы чикләрендә җир кишәрлекләре аларның милекчеләреннән, биләүчеләреннән, алардан файдаланучылардан һәм аларны арендалаучылардан тартып алынмый һәм шушы кишәрлекләр өчен билгеләнгән режимга туры китереп файдаланыла.

<u>26 статья.</u> Табигатьне саклау өчен билгеләнгән җирләр

1.Табигатьне саклау өчен билгеләнгән җирләргә түбәндәге җирләр кертелә:

а) елга-сулыкларның су саклау зоналары;

б) тыелган полосалар һәм уылдык чәчүне саклау полосалары;

в) саклау функцияләрен башкаручы урманнар;

г) уникаль типик һәм сирәк ландшафтлар;

д) эрозиягә каршы һәм кыр ышыклау өчен утыртылган урманлыклар;

е) табигатьне саклау функцияләрен үтәүче башка җирләр.

2. Табигатьне саклау өчен билгеләнгән җирләрдә, табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән килешенеп, аларны саклау режимы үтәлгән килеш, чикләнгән хуҗалык эшчәнлеге рәхсәт ителә.

3. Табигатьне саклау өчен билгеләнгән җирләр чикләрендәге җир кишәрлекләре аларның милекчеләреннән, аларны биләүчеләрдән, алардан файдаланучылардан һәм аларны арендалаучылардан тартып алынмый. Аларның кысаларында җирләрдән файдалануның зоналарны билгеләү максатларына туры килми торган эшчәнлек тәр-

ләрен чикләүче һәм тыючы махсус режим кертелә.

4. Табигатьне саклау өчен билгеләнгән җирләрдән файдалану тәртибе, җирләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны урнаштыру һәм алардан файдалану тәртибе законнар белән билгеләнә.

27 статья. Халыкны савыктыру өчен билгеләнгән җирләр

1. Халыкны савыктыру өчен билгеләнгән җирләргә табигый дәвалау ресурслары (минераль чыганаклар, дәвалау ләмнәре ятмалары), уңай климаты һәм авыруларны кисәтү һәм дәвалау өчен башка шартлары булган дәвалау-савыктыру урыннары һәм курорт җирләре керә.

2. Дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар территорияләрендә халыкның авыруларын кисәтүне һәм дәвалауны оештыру өчен уңайлы санитар һәм экологик шартларны саклап калу максатларында законнар нигезендә санитар саклау округлары билгеләнә.

3. Билгеләнгән санитар режимда җирләрне хуҗалык әйләнешеннән тулысынча төшереп калдыру каралган очраклардан гайре, дәвалау-савыктыру урыннарының һәм курортлардан (санитар саклауның беренче зонасы), җир кишәрлекләре санитар зоналары чикләрендә милекчеләреннән, биләүчеләреннән, файдаланучыларыннан һәм арендалаучыларыннан тартып алынмый.

28 статья. Рекреация өчен билгеләнгән җирләр

1. Рекреация өчен билгеләнгән җирләргә халыкның ялын, туризмны оештыру, спорт-савыктыру эшчәнлеге өчен билгеләнгән һәм файдаланылучы җирләр керә. Алар составына ял йортлары, пансионатлар, кемпинглар, спорт-савыктыру комплекслары, туристлык базалары, яхт-клублар, стационар һәм палаткалы туристлык-савыктыру лагерьлары, балыкчылар һәм аучылар йортлары, балалар туристлык станцияләре, парклар, урман парклары, укыту-туристлык сукмаклары, маркировкаланган трассалар, балалар һәм спорт лагерьлары һәм савыктыру өчен билгеләнгән җирләрдән читтә урнашкан башка шундый объектларның территорияләре биләгән җир кишәрлекләре керә.

2. Укыту-туристлык сукмаклары һәм маркировкаланган трас-

салар урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар, аларны арендалаучылар белән килешенү буенча чикләнгән кулланылыш хокукында бүлеп куела һәм алардан тартып алынмый.

3. Рекреациягә билгеләнгән җирләргә шулай ук шәһәр яны яшел зоналары җирләре дә кертелә. Аларда урман фондыннан файдалану Татарстан Республикасының урман һәм табигатьне саклау турындагы законнардагы таләпләр нигезендә башкарыла.

4. Рекреация өчен билгеләнгән җирләрдә аларны максатчыл файдалануга тоткарлык ясарлык эшчәнлек тыела.

<u>29 статья.</u> Тарихи-мәдәни билгеләнешле җирләр

1. Тарихи-мәдәни билгеләнешле җирләргә түбәндәге җир кишәрлекләре керә:

а) тарихи һәм мәдәни ядкярләр урнашкан җирләр, истәлекле, шул исәптән тарихи-мәдәни тыюлыклар (музей-тыюлыклар) итеп игълан ителгән җирләр;

б) традицион халык сәнгате һөнәрчелекләре, кәсепләре һәм башка гамәли сәнгать яшәешенә бәйле мәдәният учреждениеләре, шәһәр һәм башка урыннарның тарихи корылмалары, хәрби һәм гражданнар каберлекләре, тарихи-мәдәни ядкярләрне саклау биләгән җирләр;

в) законнар нигезендә тарихи-мәдәни билгеләнешле башка объектлар биләгән җирләр.

2. Сакланырга, тикшеренүләр уздырылырга һәм консервациялэнергә тиешле тарихи-мәдәни объектларны да кертеп, тарихи-мәдәни максаттагы җирләрдә, саклау объектын үстерүгә һәм аңа хезмәт күрсәтүгә юнәлтелгән эшчәнлектән тыш, теләсә нинди хуҗалык эшчәнлегe тыелырга мөмкин.

3. Тарихи-мәдәни билгеләнешле җирләрдән файдалану тәртибе законнар белән билгеләнә.

<u>30 статья.</u> Аеруча кыйммәтле җирләр

Аеруча кыйммәтле җирләргә махсус сакланылучы территорияләр режимы кертелгән һәм максатчыл билгеләнешен үзгәртү рөхсәт ителми торган җирләр кертелә.

Аеруча кыйммәтле җирләр турында мәгълүматлар җир кадастры, җир эшләрен алып бару һәм шәһәр төзелеше документларында күрсәтелә.

### 7 бүлек. Урман фонды, су фонды җирләре һәм запас җирләр

31 статья. Урман фонды җирләре

1. Урман фонды җирләренә урман җирләре (урман белән капланган, шулай ук урман торгызу өчен билгеләнмәгән, урман белән капланмаган - киселгән, янган, сирәкләнгән, ялангачланган һәм башка урыннар), урман хуҗалыгын алып бару өчен файдаланылучы урман булмаган җирләр (сөрүлекләр, печәнлекләр, көтүлекләр, сазлыклар, юллар, квартал ызаннары һәм башкалар) керә.

2. Авыл хуҗалыгы оешмалары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары чикләрендә урнашкан урман фонды җир кишәрлекләре авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгын комплекслы алып бару өчен аларга файдалануга яки арендага бирелергә мөмкин. Мондый кишәрлекләрдә урман фондыннан файдалану Татарстан Республикасының урман турындагы һәм табигатьне саклау турындагы законнары таләпләренә туры китереп тормышка ашырыла.

3. Урман фонды җирләрендәге урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен файдаланылмаган авыл хуҗалыгы һәм башка җирләр урман хуҗалыгына идарә итү органнары тарафыннан авыл хуҗалыгы һәм башка максатлар өчен арендага яки вакыты билгеләнгән файдалануга җирле администрацияләр белән килештерелеп бирелә.

4. Урман фонды җирләреннән файдалану тәртибе әлеге Кодекс һәм урман турындагы законнар белән җайга салына.

32 статья. Су фонды җирләре

1. Су фонды җирләренә су объектлары биләгән җирләр, шулай ук гидротехник, су хуҗалыгы корылмалары һәм су объектларыннан файдалану өчен кирәк булган башка корылмалар полосалары өчен бирелгән җирләр керә.

2. Су фонды җирләре халыкның эчәр суларга, көнкүреш, савыктыру ихтыяҗларын һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерүче

корылмалар төзү һәм эксплуатацияләү йөзеннән, шулай ук су хуҗалыгы, авыл хуҗалыгы, табигатьне саклау, сәнәгать, балыкчылык хуҗалыгы, энергетика, транспорт һәм башка дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен файдаланыла ала.

3. Су фонды җирләреннән файдалану тәртибе әлеге Кодекс һәм су законнары белән билгеләнә.

33 статья. Запас җирләр

1. Запас җирләргә дәүләт милкендә булган һәм гражданнар, юридик затлар милкенә, биләвенә, файдалануына, шул исәптән арендалавына бирелмәгән, шулай ук консервация нәтиҗәсендә хуҗалык әйләнешеннән чыгарылган җирләр керә.

2. Запас җирләр составына, урман фонды җирләреннән тыш, файдаланылмаучы һәм бушаган җир кишәрлекләре кертелергә мөмкин. Элек урман фонды җирләреннән бүлеп бирелгән файдаланылмаучы һәм бушаган җир кишәрлекләре яңадан урман фондына кайтарыла.

3. Запас җирләр башка категориягә күчерелгәч кенә алардан файдалану рөхсәт ителә.

8 бүлек. Җир ресурсларына идарә итү

34 статья. Җирләрдән файдалануны планлаштыру

1. Җирләрне хуҗалыкта һәм башкача файдалану, үзләштерү Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының һәм җирле үзидарә органнарының территория үсешен планлаштыру турындагы карарлары нигезендә башкарыла.

2. Җирләрдән файдалануны планлаштыру социаль-икътисадый программалар, җир эшләрен алып бару, шәһәр төзелеше, табигатьне саклау яки башка документлар нигезендә территорияләр үсешенең озак вакытка исәпләнгән перспективасын билгеләү максатларында тормышка ашырыла.

35 статья. Җирләрне зоналаштыру

1. Җирләрне зоналаштыру - җирләрне төрле максатчыл билге-

ләнештәге һәм төрле хокукый файдалану режимындагы кишәрлекләргә бүлү.

2.Җирләрне зоналаштыру халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле үзидарәнең тиешле органнарының карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла һәм шәһәр төзелеше, җир эшләрен алып бару документлары һәм башка документлар нигезендә тормышка ашырыла. Җирләрне зоналаштыруның төп нигезләмәләре һәм принциплары законнар белән билгеләнә.

<u>36 статья.</u> Авыл хуҗалыгы җирләрен районлаштыру

1. Җирләрне табигать-авыл хуҗалыгы буенча районлаштыру - территорияләрне туфрак, агроклимат, геоморфологик һәм авыл хуҗалыгы үсемлекләренең агробиологик таләпләренә карата кулланылышлы башка шартларны исәпкә алып бүлү ул.

2. Авыл хуҗалыгы җирләрен файдалану һәм аларны саклау республика территориясендәге җирләрне табигать-авыл хуҗалыгы буенча районлаштыру нигезендә тормышка ашырыла.

3. Авыл хуҗалыгы җирләрен табигать-авыл хуҗалыгы буенча районлаштыру турындагы норматив-хокукый актларның таләпләре җир кишәрлекләренә карата законнарда билгеләнгән йөкләүләргә кертелә һәм аларны бирү шартларына керә.

<u>37 статья.</u> Җир эшләрен алып бару

1. Җир эшләрен алып бару җирдән файдалануны оештыруга, җир ресурсларын исәпкә алуга һәм бәяләүгә, территория һәм хуҗалык эчендәге планнар төзүгә юнәлдерелгән чаралар системасыннан гыйбарәт.

2. Җир эшләрен алып баруга түбәндәгеләр керә:

а) территориянең шәһәр төзелеше, экологик, икътисадый һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, җир ресурсларыннан файдалану һәм аны саклауның республика һәм җирле программаларын, җир эшләрен алып бару схемаларын әзерләү;

б) җирләрне ызанлау -җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләү, чикләрне урнаштыру һәм җир кишәрлекләрен натурада (урында) бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләренең планнарын (сызымнарын) рәсмиләштерү, җир кишәрлекләренә хокукны таныклау өчен

документлар әзерләү;

в) хуҗалыкара, хуҗалык эчендә җир эшләрен алып бару проектлары һәм җирләрдән файдалану һәм аны саклау белән бәйле башка проектлар әзерләү;

г) бозылган җирләрне рекультивацияләү, туфракны су һәм җил эрозиясеннән, туфрак шуышулардан, су басулардан, сазлыклanудан, кибүдән, тыгызланудан, тозланудан, җитештерү калдыклары, химик һәм радиоактив матдәләр белән пычранудан яклау, авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрен яхшырту, яңа җирләр үзләштерү, туфракның уңдырышлылыгын саклап калу һәм арттыру буенча эшче проектлар әзерләү;

д) махсус сакланылучы территорияләрнең урнашуын һәм чикләрен билгеләүне нигезләү;

е) урыннарда торак пунктлары сызыкларын беркетү;

ж) топография-геодезия, картография, туфрак, агрохимия, геоботаника һәм башка тикшеренү һәм эзләнү эшләрен башкару;

з) җирләрне ресурс ягыннан бәяләүгә, алардан файдалануга һәм аларны саклауга бәйле җир эшләрен алып бару документларын әзерләү;

и) барлык җирләрне инвентарьлаштыру һәм файдаланылмаучы, нәтиҗәсез файдаланылучы яки максатчыл билгеләнеше буенча файдаланылмаучы җирләрне системалы рәвештә ачыклау;

к) җир ресурсларының торышы һәм алардан файдалану буенча кадастр, тематик карталар һәм атласлар төзү;

л) җир бәяләү эшләрен үткәрү.

3. Җир эшләрен алып бару Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең тиешле органнары, шулай ук җир ресурслары һәм җир реформасы комитетлары инициативасы буенча җирле үзидарә органнары карары нигезендә Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән, яисә җир кишәрлекләре милекчеләре, биләүчеләре, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар үтенече буенча кызыксынучы як акчалары исәбеннән үткәрелә.

4. Җир эшләрен алып бару җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар, аларны арендалаучылар катнашында үткәрелә. Җир эшләрен алып бару проектлары, расланганнан соң, җир кишәрлекләренең чикләрен һәм чәчү әйләнеше кырларын, билгеләнгән үрнәктәге тамгалар белән билгеләп,

натурага (урынга) күчерелә.

5. Җир эшләрен алып бару эшләре эшчәнлек төренә лицензиясе булган дәүләтнең җир эшләрен алып бару буенча проект оешмалары, шулай ук башка оешмалар һәм гражданнар тарафыннан башкарыла.

6. Җир эшләрен алып бару тәртибе законнар нигезендә урнаштырыла.

38 статья. Җирләрнең мониторингы

1. Җирләрнең мониторингы җирләрнең торышын системалы күзәтүдән (сурәткә төшерүдән, тикшерүдән һәм эзләнүдән) гыйбарәт.

Татарстан Республикасының барлык җирләре җирләрнең мониторингы объекты булып тора.

2. Җирләрнең мониторингы бурычлары:

а) җирләрнең торышы үзгәрешләрен үз вакытында ачыклау, бу үзгәрешләргә бәя бирү, тискәре процессларны кисәтү һәм бетерүне фаразлау һәм тәкъдимнәр әзерләү;

б) дәүләт җир кадастрын алып баруны, җирләрдән нәтиҗәле файдалануны, җир эшләрен алып баруны, җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны, тикшерүне һәм җир ресурсларына дәүләт идарәсенең башка вазыйфаларын мәгълүмати тәэмин итү.

3. Территорияләрнең максатларына һәм зурлыгына карап, җирләрнең мониторингы федераль, республика һәм җирле мониторингка бүленә.

4. Татарстан Республикасында җирләрнең мониторингы Россия Федерациясе җирләре мониторингының состав өлеше булып тора, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә федераль бюджет, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән башкарыла.

39 статья. Дәүләт җир кадастры

1. Дәүләт җир кадастры җирләрнең табигый, хуҗалык һәм хокукый хәле, җир кишәрлекләренең урыны һәм зурлыгы, аларның сыйфат характеристикасы, җирдән файдалану режимы, җир кишәрлекләрен биләүчеләр турында, җир кишәрлекләрен исәпкә алу һәм

бәяләү турында дөрес мәгълүматлар һәм башка кирәкле мәгълүматлар системасыннан гыйбарәт. Дәүләт җир кадастры табигать ресурсларының тармак кадастрлары өчен нигез булып тора.

2. Дәүләт җир кадастры мәгълүматлары җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны планлаштырганда, җир кишәрлекләрен биргәндә һәм тартып алганда, җир кишәрлекләре турында алыш-биреш килешүләре төзегәндә, җир өчен түләүләрнең күләмнәрен билгеләгәндә, җир эшләрен алып баруны башкарганда, хуҗалык эшчәнлеген бәяләгәндә һәм җирләрдән файдалануга, аларны саклауга бәйле башка чараларны тормышка ашырганда кулланылалар.

3. Татарстан Республикасының дәүләт җир кадастры бөтен Россия Федерациясе өчен бердәм система буенча федераль бюджет, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән, шулай ук җир кадастры мәгълүматларын бирүгә, җир турында алыш-биреш килешүләрен төзүне рәсмиләштерүгә бәйле төрле хезмәт күрсәтүләр өчен түләү рәвешендә физик һәм юридик затлардан керүче акчалар исәбеннән алып барыла.

4. Дәүләт җир кадастрын алып бару тәртибе законнар белән билгеләнә.

<u>40 статья.</u> Җир ресурсларын бәяләү

1. Җир ресурсларын бәяләү - туфракның уңдырышлылыгын, табигый һөм икътисадый шартларны, зоналаштыру һәм районлаштыру нигезендә җир кишәрлекләренең урнашкан урыннарын исәпкә алып, рента нигезендә җир кишәрлекләренең кадастр хакын билгеләү ул.

Җир ресурсларын бәяләгәндә җирләрнең мониторингы, дәүләт җир кадастрының, җир торышы буенча билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган башка тикшеренүләрнең һәм күзәтүләрнең мәгълүматлары кулланыла.

2. Җир ресурсларын бәяләү өчен билгеләнгән тәртиптә бәяләү комиссияләре төзелә, алар составына тиешле лицензияләре булган дәүләт экспертлары һәм бәйсез экспертлар керә.

3. Җир кишәрлекләренең кадастр (норматив) хакы турында билгеләнгән мәгълүматлар җир өчен түләүне билгеләгәндә һәм җир әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салганда кулланыла.

4. Җир ресурсларын бәяләүне уздыру тәртибе, шулай ук җир өчен түләүне билгеләү һәм җир өчен түләүләрдән алынган акча-

ларны куллану тәртибе җирләрне бәяләү турындагы һәм җир өчен түләү турындагы законнар белән җайга салына.

## 9 бүлек. Җирләрне саклау

### 41 статья. Җирләрне саклауның максатлары һәм бурычлары

1. Җирләрне саклау җирләрдән нәтиҗәле файдалануга һәм аларны саклауга, туфракның уңдырышлылыгын саклап калуга һәм арттыруга, авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы әйләнешеннән аеруча кыйммәтле җирләрне нигезсез тартып алуны рөхсәт итмәүгә юнәлдерелгән хокукый, оештыру, икътисадый, технологик һәм башка чаралар системасын үз эченә ала.

2. Җирләрне саклауның максатлары һәм бурычлары:

а) җитештерүнең һәм агротехник, урман-мелиоратив һәм башка туфрак яклау чараларын үткәрүнең экологик хәвефсез технологияләрен куллануга кызыксындыру юлы белән туфракны саклап калу, җирләрнең деградацияләнүен һәм бозылуын, хуҗалык эшчәнлегенең башка уңайсыз нәтиҗәләрен кисәтү;

б) деградацияләүгә яки бозылуга дучар ителгән җирләрне яхшырту һәм торгызуны тәэмин итү;

в) җирдән файдалануның экологик нормативларын гамәлгә кертү;

г) территорияне нәтиҗәле оештыру.

3. Җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар түбәндәге чараларны үткәрергә бурычлылар:

а) туфракны саклап калу һәм уңдырышлылыгын арттыру;

б) җирләрне су һәм җил эрозиясеннән, су басудан, сазлыклanудан, икенчел тозланудан, кибүдән, тыгызланудан, җитештерү һәм куллану калдыклары, пычрак сулар, химик һәм радиоактив матдәләр белән пычранудан һәм туфракның деградацияләнүенә китерүче башка гамәлләрдән яклау;

в) авыл хуҗалыгының уңдырышлы басу-кырларын һәм башка җирләрне бактерия-паразит һәм карантин корткычлар, үсемлек авырулары белән зарарланудан, чүп-үләннәр, куаклыклар һәм вак урманнар басып китүдән, җирләрнең торышын начарайтуның башка төрләреннән саклау;

г) бозылган җирләрне рекультивацияләү, аларның уңдырышлылыгын арттыру, аларны хуҗалык әйләнешенә үз вакытында кертү;

д) җирләрнең бозылуына бәйле эшләр үткәргәндә туфракның уңдырышлы катламын саклап калу һәм аны файдалану.

4. Химик һәм (яки) радиоактив матдәләр, җитештерү калдыклары, пычрак сулар белән билгеләнгән иң чик мөмкин нормалардан артыграк пычранган, бактерия-паразит һәм карантин корткычлары, үсемлек авырулары белән зарарланган һәм деградацияләнгән җирләрнең уңдырышлылыгын торгызып булмаган очракларда, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә әлеге җирләрне консервацияләү карала.

5. Җирләрне саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану җирләрне саклау буенча, туфракның уңдырышлылыгын арттыру, мониторинг, җир кадастры алып бару буенча республика һәм җирле программалар нигезендә тормышка ашырыла.

6. Кеше сәламәтлеген саклау һәм әйләнә-тирә табигать мохитен яклау мәнфәгатьләрендә зарарлы матдәләр, зарарлы микроорганизмнар һәм җирне пычратучы башка биологик матдәләр концентрациясенең билгеләнгән иң чик нормативлары урнаштырыла.

<u>42 статья.</u> Җирләрне саклауны икътисадый кызыксындыру

1. Җирләр саклауны икътисадый кызыксындыру җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның туфракның уңдырышлылыгын саклап калуга һәм арттыруга, җирләрне хуҗалык эшчәнлегенең тискәре нәтиҗәләреннән яклау белән кызыксынуларын арттыруга юнәлдерелгән.

2. Җирләрне саклауны икътисадый кызыксындыру түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) федераль бюджеттан, Татарстан Республикасының республика бюджетыннан, җирле бюджетлардан бүлеп бирелгән һәм штрафлардан, башка чыганаклардан кергән акчаларны туфракның уңдырышлылыгын арттыруның федераль, республика һәм җирле программалары нигезендә җирләрне торгызуга, агротехник, урман-мелиоратив һәм туфракны яклауның башка чараларын үткәрүгә куллanudан;

б) эшләрне башкару проектында каралган чорга авыл хуҗалы-

гы үзләштерүе стадиясендә булган җир кишәрлекләре өчен түләүдән азат итүдән;

в) табигый бәла-казалар һәм табигать күренешләре аркасында бозылган җирләрне вакытлы консервацияләү нәтиҗәсендә керемнәр кимүдән килеп чыккан зыянны федераль бюджет, Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар акчаларыннан компенсацияләүдән.

3. Җирләрне саклау, туфракның уңдырылышлылыгын арттыру буенча җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар тоткан чыгымнарны тулысынча һәм өлешчә түләттерү федераль, республика һәм җирле программалар нигезендә федераль бюджеттан, Татарстан Республикасының республика бюджетыннан, җирле бюджетлардан башкарыла.

<u>43 статья.</u> Җирләрнең торышына йогынты ясаучы биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны һәм башка объектларны проектлауга, файдалануга тапшыруга карата экология, санитария-гигиена таләпләре һәм башка махсус таләпләр

1. Яңа һәм реконструкцияләнүче биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, проектлаштырганда һәм файдалануга тапшырганда, яңа техника һәм технологияләрне гамәлгә керткәндә, җирләрне саклау, экология, санитария-гигиена таләпләрен һәм башка махсус таләпләрне (нормаларны, кагыйдәләрне, нормативларны) үтәү гамәлләре күздә тотылырга һәм башкарылырга тиеш.

2. Җирләрнең торышына тискәре йогынтыга һәм җирләрне саклау буенча каралган гамәлләрнең нәтиҗәлелегенә бәя бирү дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре буенча башкарыла, уңай бәяләмә булмаса, яңа техника һәм технологияләр кертү, җирләрне мелиорацияләү программаларын гамәлгә ашыру, җитештерү объектлары һәм башка объектлар төзүне (реконструкцияләүне) финанслау тыела.

<u>44 статья.</u> Радиоактив һәм химик пычрануга дучар булган җирләрдән файдалану

1. Билгеләнгән таләпләргә (нормаларга, кагыйдәләргә, нор-

мативларга) җавап бирә торган продукция белән тәэмин итмәүче һәм радиоактив һәм химик пычрануга дучар булган җир кишәрлекләре авыл хуҗалыгы файдалануыннан төшеп калырга тиеш. Мондый җирләрдә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм аны сату тыела.

2. Радиоактив һәм химик пычрануга дучар булган җирләрдән файдалану, саклау зоналары билгеләү, бу җирләрдә торак йортларны, җитештерү һәм социаль-мәдәни объектларны калдыру, аларда мелиорация һәм культураларны техник эшкәртү эшләрен алып бару тәртибе, радиация һәм химия тәэсиренең рөхсәт ителгән иң чик дәрәҗәдәге нормативларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

<u>45 статья.</u> Җир турындагы законнарның үтәлешен, җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору

1. Җир турындагы законнарның үтәлешен, җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны үз компетенцияләре чикләрендә Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, шул исәптән җирләрдән файдалануны һәм аны саклауны тикшереп тору буенча махсус вәкаләтле дәүләт органнары законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Җир турындагы законнарның үтәлешен, җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

## 10 бүлек. Татарстан Республикасында җир кишәрлекләренә милекчелек хокукы һәм башка хокуклар

<u>46 статья.</u> Җир кишәрлекләренә милекчелек хокукы һәм башка хокуклар

1. Татарстан Республикасында җир кишәрлекләре хосусый милектә, дәүләт милкендә, җирле үзидарә милкендә һәм башка милек рәвешләрендә була алалар.

Гражданнар һәм юридик затлар, шул исәптән чит ил гражданнары һәм юридик затлары, гражданлыксыз затлар әлеге Кодекс ни-

гезендә милекчелек хокукында җир кишәрлекләренә ия була алалар.

2. Гражданнар, шул исәптән чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар шулай ук түбәндәге хокукларда да җир кишәрлекләренә ия була алалар:

гомер буе мирас итеп биләү;

даими (вакыты чикләнмичә) файдалану;

вакытын чикләп файдалану;

арендалау.

3. Юридик затлар, шул исәптән чит илнекеләр дә, җир кишәрлекләренә шулай ук түбәндәге хокукларда да ия була алалар:

даими (вакыты чикләнмичә) файдалану;

вакытын чикләп файдалану;

арендалау.

47 статья. Җир кишәрлекләренә дәүләт милке хокукы

1. Гражданнар, юридик затлар һәм җирле үзидарә милкенә тапшырылган җир кишәрлекләреннән гайре, Татарстан Республикасының барлык җирләре дәүләт милкендә була.

2. Дәүләт милке Татарстан Республикасы милкендә булган (республика милкендәге) җирләрдән тора.

3. Республика милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итүне һәм эш итүне Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары әлеге Кодекста, Татарстан Республикасының башка законнарында һәм бүтән норматив-хокукый актларында билгеләнә торган компетенция чикләрендә гамәлгә ашыралар.

48 статья. Җир кишәрлекләренә җирле үзидарәнең милекчелек хокукы

1. Җирле үзидарә булган шәһәрләрдә һәм авылларда, шулай ук башка территорияләрдә милекчелек хокукындагы җирләр җирле үзидарә милке була.

2. Дәүләт милкендәге һәм хосусый милеккә тапшырылган җирләрдән гайре, авыл чик сызыгы кысаларындагы барлык җирләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары тарафыннан җирле үзидарә милкенә тапшырылган авыл чиге сызыгыннан

читтәге җир кишәрлекләре җирле үзидарә милке булалар.

3. Җирле үзидарә милкенә аларның үсешен тәэмин итү өчен дәүләт милкендәге җирләр өстәмә рәвештә түләүсез тапшырылырга мөмкин.

4. Җир кишәрлекләренең милекчеләреннән аларны сатып алу яисә бүләк итү, җир кишәрлекләреннән баш тарту һәм башка законлы нигезләрдә җирләр җирле үзидарә милкенә алынырга мөмкин.

5. Җирле үзидарә милкендәге җирләр белән идарә итүне һәм эш итүне җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

6. Җирле үзидарә милкендәге җирләр җирле үзидарә органнарының карарлары нигезендә гражданнар һәм юридик затлар милкенә сатып бирелергә һәм (яисә) даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга, гомерлек мирас итеп биләүгә, арендага яисә вакыты чикләнеп файдалануга тапшырылырга мөмкин.

<u>49 статья.</u> Җир кишәрлекләренә хокукларның барлыкка килү нигезләре

Гражданнарның һәм хокукый затларның җир кишәрлекләренә хокуклары түбәндәгеләр нигезендә барлыкка килә:

Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары актлары;

сату-алу шартнамәләре һәм җир кишәрлекләре белән башка алыш-биреш гамәлләре;

дәүләт милкендәге җир кишәрлекләренә милек хокукларыннан гайре,билгеләнгән файдалану чоры узып алынган милек хокукы;

суд карары;

закон яисә бүтән норматив акт нигезендә гражданнарның җир кишәрлекләре хокукларына һәм алардан файдалану вазыйфаларына бәйле башка гамәлләр, шулай ук вакыйгалар.

<u>50 статья.</u> Җир кишәрлегенә хосусый милекчелек хокукы

1. Гражданнарның һәм юридик затларның җир кишәрлегенә милекчелек хокукы - законда билгеләнгән барлык йөкләтүләрне һәм шартларны үтәп, җир кишәрлеген биләү, аннан файдалану, аңа идарә итү хокукы ул.

2. Җир кишәрлегенә хосусый милекчелек хокукы дәүләт мил-

кендәге яисә җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлекләрен законнар нигезендә хосусыйлаштыру, мирас итеп тапшыру, сату-алу, бүләк итү, алмаштыру, юридик затның устав капиталына кертү һәм бүтән алыш-биреш гамәлләре башкару нәтиҗәсендә барлыкка килә.

<u>51 статья.</u> Җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукы

1. Дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлеген гражданның гомерлек мирас итеп биләү хокукы әлеге Кодекста каралган нигезләрдә һәм тәртиптә алына.

2. Гомерлек мирас итеп биләү хокукына ия граждан мирас буенча тапшырыла торган җир кишәрлеген биләү һәм аннан файдалану хокукына ия.

3. Җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукына ия булган биләүче аны башка затларга арендага яисә түләүсез вакытлы файдалануга тапшырырга мөмкин.

4. Җир кишәрлеген читләштерерлек яисә читләштерергә мөмкин булырлык итеп биләүче тарафыннан җир кишәрлеген сату, залогка салу һәм башка алыш-биреш гамәлләре кылу рөхсәт ителми.

5. Җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукына ия булган граждан аны әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә үз милкенә сатып алырга яисә түләүсез алырга хокуклы.

<u>52 статья.</u> Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукы

1. Дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукы гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органы яисә җирле үзидарәнең җир кишәрлекләрен шундый файдалануга тапшырырга вәкаләтле органы карары нигезендә бирелә.

2. Башка затның җир кишәрлегендәге бина, корылма яисә бүтән күчемсез мөлкәт милекчесе шушы зат тарафыннан әлеге күчемсез мөлкәт өчен бирелгән җир кишәрлегеннән файдаланырга хокуклы.

Әгәр законнан, дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә мил-

кендәге җирне бирү карарыннан яисә шартнамәдән башкасы килеп чыкмаса, бина яисә корылма милекчесе шушы күчемсез мөлкәт урнашкан җир кишәрлеге өлешеннән даими файдалану хокукына ия була.

3. Даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга җир кишәрлеге тапшырылган зат:

- законда, башка хокукый актларда һәм файдалануга җир кишәрлеге бирү турындагы актта билгеләнгән чикләрдә шушы кишәрлекне били һәм аннан файдалана;
- әгәр законда башкача каралмаган булса, әлеге кишәрлектән, ул нинди максатлар өчен бирелгән булса, шул максатларда, кишәрлектә биналар, корылмалар һәм башка күчемсез мөлкәт төзүне дә кертеп, файдаланырга хокуклы. Бу затның үзе өчен төзегән биналары, корылмалары, башка күчемсез мөлкәте аның милке була;
- бу кишәрлекне яисә аның бер өлешен башка затларга арендага яисә вакытын чикләп файдалануга бары тик шушы җир кишәрлегенең милекчесе ризалыгы белән генә тапшыра ала.

53 статья. Җир кишәрлеген арендалау хокукы

1. Арендалау хокукы - арендалаучының җир кишәрлеге милекчесе белән төзегән шартнамәсе шартларында җир кишәрлеген түләүле рәвештә вакытлы биләү яисә аннан вакытлы файдалану хокукы ул.

Арендага бирүче ризалыгы белән арендалаучы арендаланган җир кишәрлеген субарендага бирергә, шулай ук аренда хокукларын залогка бирергә хокуклы.

Субаренда шартнамәсе аренда шартнамәсенең вакытыннан да озаккарак төзелә алмый.

2. Дәүләт милкендәге, җирле үзидарә милкендәге, хосусый милектәге, гомерлек мирас итеп биләүдәге һәм даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылган җирләрдәге җир кишәрлекләре арендага бирелергә мөмкин.

Дәүләт милкендә, җирле үзидарә милкендә булган җирләрнең җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукы сәүдә нокталарында сатылырга мөмкин.

3. Җир кишәрлеген арендалау чоры 50 елдан да артмаска тиеш. Бу очракта, әгәр дә законда яисә аренда шартнамәсендә баш-

кача каралмаган булса, үз вазыйфаларын тиешенчә башкарган арендалаучы, шартнамә вакыты узганнан соң, бүтән бертигез шартларда аренда шартнамәсен яңа вакытка төзү буенча башка затлар белән чагыштырганда өстенлекле хокукка ия була.

54 статья. Җир кишәрлегеннән вакытын чикләп файдалану хокукы

Җир кишәрлегеннән вакытын чикләп файдалану хокукы - түләүсез файдалану шартнамәсе шартларында өч елга кадәр җир кишәрлегеннән файдалану ул.

Милекче һәм гомерлек мирас итеп биләү һәм даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукында җир кишәрлекләре булган затлар җир кишәрлеген яисә аның бер өлешен вакытын чикләп файдалануга бирү хокукына ия булалар.

55 статья. Җир кишәрлегенә гомуми милекчелек, аны биләү, аннан файдалану һәм аны арендалау хокукы

1. Ике яисә күбрәк затның милкендә, гомерлек мирас итеп биләвендә, вакытын чикләп (вакыты чикләнмичә) файдалануында, арендалавында булган җир кишәрлеге аларның гомуми милекчелек, арендалау, гомуми гомерлек мирас итеп файдалану, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану (гомуми биләү) хокукында булалар.

2. Максатчыл билгеләнешен үзгәртмичә бүленми торган яисә закон нигезендә бүленергә тиеш булмаган җир кишәрлеге ике яисә берничә затның милкендә, гомерлек мирас итеп биләвендә, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануында, арендалавында булганда, шулай ук биләүчеләр тарафыннан аларның җир кишәрлекләре килешү буенча ихтыярый рәвештә бер җир кишәрлегенә берләштерелгәндә җир кишәрлеген гомуми биләү хокукы бирелә.

3. Биналар, корылмалар, төзелмәләр биләгән җир кишәрлекләре, шулай ук крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару, терлекчелек, бакчачылык, яшелчәчелек, индивидуаль торак, дача, гараж төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләре ике яисә аннан да күбрәк зат биләвендә булганда, гражданнарга һәм юридик затларга әлеге статьяның 2 пункты кагыла.

4. Җир кишәрлеге гомуми биләү хокукында һәр биләүченең

өлешен билгеләп тә (өлешле биләү) һәм андый өлешләрне билгеләмичә дә (уртак биләү) була ала.

Ир белән хатын, гаилә крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар өчен җир кишәрлеген гомуми уртак биләү рөхсәт ителә.

5. Ир белән хатынның берәрсе милкенә тапшырылган яисә алыш-биреш гамәлләре нәтиҗәсендә йә законнарда каралган башка нигезләрдә алар тарафыннан алынган җир кишәрлеге, әгәр шартнамәдә башкача каралмаган булса, өйләнешкәч, ир белән хатынның уртак милке була.

<u>56 статья.</u> Җир кишәрлегендә төзү хокукы

1. Җир кишәрлегендә төзү хокукы милекчелек хокукында, гомерлек мирас итеп биләү, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану һәм арендалау хокукында җир кишәрлегенә ия булган гражданнар тарафыннан максатчыл билгеләнеше нигезендә, шәһәр төзелеше, төзелеш, экология нормаларын һәм башка нормаларны, кагыйдәләрне һәм стандартларны үтәгән килеш гамәлгә ашырыла.

Вакытын чикләп файдалануга бирелгән җир кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар төзү рөхсәт ителә, файдалану вакыты чыкканнан соң алар җир кишәрлегеннән файдаланучы исәбеннән сүтелергә тиеш.

2. Җир кишәрлеген милеккә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, арендага яисә күчемсез мөлкәт белән алыш-биреш гамәлләре кылу нәтиҗәсендә алган гражданнар һәм юридик затлар, шәһәр төзелеше, торак һәм башка законнар нигезендә, җир кишәрлегенә карата куелган йөкләмәләрнең шартларын үтәгән, аның максатчыл билгеләнешен саклаган килеш, җир кишәрлегендә төзергә, сүтәргә яисә сатып алынган корылмаларны реконструкцияләргә хокуклы.

3. Билгеләнгән тәртиптә төзелеш проектын килештергәннән, төзелешкә рөхсәт алганнан соң төзү хокукы барлыкка килә.

<u>57 статья.</u> Җир кишәрлеген йөкләтү

1. Җир кишәрлеге дәүләт милкендәге һәм җирле үзидарә милкендәге җирләрдән бирелгәндә йә законнарда каралган нигезләрдә

сатып алынганда, аңа түбәндәге йөкләмәләр йөкләтелергә мөмкин:

а) аерым затларга сатуны яисә башкача читләштерүне тыю йә вакыты чикләнмичә яисә билгеләнгән вакыт эчендә аерым затларга читләштерүгә рөхсәт бирү;

б) арендага яисә субарендага бирүне тыю;

в) аны сатканда игълан ителгән бәя буенча сатып алырга өстенлекле хокук;

г) билгеләнгән сервитутларны үтәү;

д) мәгълүм тәртиптә килештерелгән проект буенча билгеләнгән вакыт эчендә төзелеш башлау һәм тәгәлләү шарты яисә җир кишәрлеген үзләштерү;

е) билгеләнгән тәртиптә килештермичә күчемсез мөлкәтнең тышкы күренешен үзгәртүне яисә бинаны, корылманы, төзелмәне реконструкцияләүне тыю;

ж) төзү, ремонтлау яисә юллар һәм юлларның бер өлешен тоту шарты;

з) эшчәнлекнең аерым төрләрен яисә алып бару рәвешләрен тыю;

и) җир кишәрлегеннән максатчыл файдалануны үзгәртүне тыю;

к) табигатьне саклау таләпләрен үтәү яисә аерым эшләрне башкару, шул исәптән җир кишәрлегендәге хайваннар дөньясын, туфрак өслеген саклау, сирәк очрый торган үсемлекләрне, табигать, тарих, мәдәният ядкярләрен, археологик объектларны саклау шартлары;

л) билгеләнгән вакытта һәм билгеләнгән тәртиптә үз кишәрлегендә аулау, балык тоту, кыргый үсемлекләр җыю хокукын бирү шартлары;

м) кыргый хайваннарның табигый яшәү тирәлеген һәм миграция юлларын саклау шарты;

н) башка йөкләмәләр, чикләүләр яисә шартлар.

2. Җир кишәрлеген йөкләтү турыдан-туры законнар, шартнамәләр яисә суд карары белән билгеләнә.

3. Җир кишәрлеген йөкләтүләр аның хокукый статусына кертелә, алар дәүләт теркәвенә алынырга тиеш һәм җир кишәрлеге башка затка күчкәндә сакланалар.

58 статья. Җир кишәрлегенә сервитут

1. Сервитут - чит җир кишәрлегеннән (кишәрлекләреннән) чикләүле файдалану хокукы ул.

Чит җир кишәрлегеннән чикләүле файдалану хокукы сервитут урнаштыруны таләп итүче зат һәм җир кишәрлеге милекчесенең үзара килешүе белән яисә, килешүгә ирешелмәгән очракта, суд карары белән билгеләнә.

2. Түбәндәге сервитутлар билгеләнергә мөмкин:

а) җир кишәрлеге аша җәяү яисә транспортта үтеп йөрү;

б) җир кишәрлегеннән коммуналь яисә индивидуаль инженерлык, электр һәм башка линияләр, челтәрләр үткәрү һәм ремонтлау өчен файдалану;

в) җир кишәрлегендә дренаж эшләре башкару;

г) су алу һәм эчәр су урыннары;

д) җир кишәрлеге аша көтү үткәрү;

е) үз кишәрлегендәге бинаны, төзелмәне яисә корылманы күрше кишәрлеккә терәп яисә билгеле бер биеклектә күрше кишәрлеккә салынып тора торган итеп салу;

ж) бинаны, төзелмәне яисә корылманы тиешле биеклектән югарырак итеп салуны тыю;

з) җир кишәрлеген биләүченең сервитутлар билгеләмичә тәэмин итеп булмый торган башка ихтыяҗлары.

3. Үзләренә карата сервитут билгеләнгән кишәрлекләр өчен ул иң аз йөкләтелгән алым белән гамәлгә ашырылырга тиеш.

Әгәр законда башкасы каралмаган булса, сервитут йөкләтелгән җир кишәрлеге милекчесе сервитут ихтыяҗлары билгеләнгән затлардан кишәрлектән файдаланган өчен тиешле күләмдә түләү таләп итәргә хокуклы.

4. Сервитут вакытын чикләп яисә даими булырга мөмкин.

Сервитутлар күчемсез мөлкәткә хокукларны теркәү өчен билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узарга тиеш.

Сервитут белән йөкләтелгән җир кишәрлегенә хокуклар башка затка күчкәндә, сервитут саклана.

Сервитут билгеләү нигезләренең юкка чыгуы белән сервитут туктатылырга мөмкин. Сервитут йөкләтелү нәтиҗәсендә җир кишәрлегеннән билгеләнеше буенча файдаланып булмаганда, милекче сервитутны суд карары нигезендә туктатуны таләп итәргә хокуклы.

## 11 булек. Дәүләт җирләреннән һәм җирле үзидарә җирләреннән җир кишәрлекләре бирү

**59 статья.** Татарстан Республикасы дәүләт идарә органнарының һәм җирле үзидарә органнарының җир кишәрлекләре бирү буенча компетенцияләре

1. Җирле үзидарә милкендәге җирләрдән җир кишәрлекләре гражданнар һәм юридик затлар милкенә, аларга гомерлек мирас итеп биләүгә, файдалануга, шул исәптән арендага - җирле үзидарәнең вәкаләтле органы карары буенча, республика милкендәге җирләрдән җирле администрацияләр карары буенча бирелә, урман фондының урман хуҗалыгында файдалану максатына бәйле булмаган җирләре, шәһәрләрнең яшел зоналары биләп тора торган җирләре, су саклау һәм яклау зоналары биләгән җирләр, кадастр бәяләмәсе райондагы уртача күрсәткечтән артып киткән, авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен файдаланылмый торган сөрүлекләр һәм башка уңдырышлы авыл хуҗалыгы җирләре; хәрби частьләрне, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби уку йортларын, учреждениеләрен, предприятиеләрен һәм оешмаларын, оборона һәм иминлек өлкәсендә бурычларын үтәүче башка министрлыкларның һәм ведомстволарның гаскәрләрен урнаштыру һәм аларның даими эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән җирләр; Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча бирелә торган шәһәр яны зоналары җирләре моңа керми.

2. Җир кишәрлекләре җир төзү эшләрен оештыру һәм шәһәр төзелеше документлары нигезендә тартып алу яисә аерып алу юлы белән әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**60 статья.** Гражданнарга һәм юридик затларга җир кишәрлекләре бирүнең гомуми кагыйдәләре

1. Дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлекләрен алырга теләүче гражданнар һәм юридик затлар Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, тиешле җирле администрациягә яисә җирле үзидарә органына (алга таба - вәкаләтле органнарга) гариза бирәләр.

Гаризада җир кишәрлегеннән файдалануның максаты, күздә

тотылган үлчәмнәре, урнашу урыны, әлеге җир кишәрлегенә теләгән хокукы (милек, гомерлек мирас итеп биләү, файдалану, шул исәптән аренда) күрсәтелергә тиеш.

Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында материаллар әзерләүне, архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары, дәүләт идарәсенең җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны тикшереп торучы махсус вәкаләтле органнары белән бергәләп, җир ресурслары белән идарә итү органнары гамәлгә ашыралар.

2. Әгәр гаризада конкрет җир кишәрлеге күрсәтелсә, вәкаләтле орган тиешле килештерүләрне билгели, җир кишәрлекләреннән файдаланучы башка затларның һәм күршеләрнең хокукларын һәм өстенлекләрен ачыклый, шәһәр төзелеше документлары нигезендә аннан күрсәтелгән максатта файдалану мөмкинлеген билгели һәм, мәсьәлә уңай хәл ителгәндә, җир һәм гражданлык законнары нигезендә җир кишәрлеген бирү (сату) буенча шартнамә шартларын әзерли.

3. Әгәр мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген кайдан алырга теләвен конкрет күрсәтмәсә, мөмкин булган вариантлар тәкъдим ителә.

4. Мөрәҗәгать итүче бүлеп бирелә торган җир кишәрлегенең тиешле шартларын килештерүне үз көче һәм үз исәбеннән башкара.

5. Вәлкаләтле органның объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турындагы карары проектлау документларын әзерләү өчен нигез була. Проектны раслаганнан соң һәм объектны төзелеш планына керткәннән соң алдан килешенгән җир кишәрлеген бирү турында карар кабул ителә. Авыл хуҗалыгы җитештерүе, урман хуҗалыгы өчен, планлаштыруның һәм төзүнең генераль планнары һәм проектлары нигезендә шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларында объектлар төзү өчен җирләр бирелгән очракларда, шулай ук гражданнарга җирләр биргәндә объектны урнаштыру урынын алдан килештерү үткәрелми.

6. Җир кишәрлеген бирү, шул исәптән бүлеп бирүне килештерү тәртибе һәм вакытлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының яисә җирле үзидарә органнарының җир кишәрлеге бирү турында үз компетенцияләре чикләрендә кабул иткән карарлары җир кишәрлегенә хокукны раслый торган документлар бирү өчен нигез була.

8. Җир кишәрлеге бирүдән баш тарту вәкаләтле орган карары белән рәсмиләштерелә, һәм ул дәлилләнгән булырга тиеш. Баш тарту турындагы карарның күчермәсе мөрәҗәгать итүчегә карар чыгарылганнан соң 7 көн эчендә тапшырыла.

9. Вәкаләтле органның гражданнарга һәм юридик затларга җир кишәрлекләрен бирүдән баш тартуына суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

<u>61 статья.</u> Җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә бирү шартлары

1. Җир кишәрлекләрен юридик затлар һәм гражданнар милкенә бирү, әлеге Кодексның шушы статьясындагы 2 пунктында һәм 95 статьсында каралган очраклардан гайре, түләүле башкарыла.

Чит ил гражданнарына һәм юридик затларына, гражданлыксыз затларга милеккә җир кишәрлекләре бирү бары тик түләүле нигездә генә башкарыла.

2. Гражданнар милкенә җир кишәрлекләре түбәндәге очракларда түләүсез тапшырыла:

а) крестьян (фермер) хуҗалыгының һәр әгъзасына җирне милеккә түләүсез тапшыруның район буенча уртача нормасы чикләрендә исәпләп, крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен;

б) җир кишәрлекләренең әлеге Кодекста билгеләнгән нормаларының максималь күләмнәрен арттырмыйча, авыл җирләрендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек өчен;

в) җир кишәрлекләренең әлеге Кодекста билгеләнгән нормаларының максималь күләмнәрен арттырмыйча, индивидуаль торак, дача һәм гараж төзү өчен, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек өчен файдалануга яисә биләүгә билгеләнгән тәртиптә 1993 елның 5 июненә кадәр бирелгән җир кишәрлекләре.

3. Әлеге статьяның 2 пунктында каралган максатлар өчен гражданнарга җир кишәрлеген кабат түләүсез бирү рөхсәт ителми.

<u>62 статья.</u> Җир кишәрлекләрен бирү нормалары

1. Гражданнарга, хуҗалык исәбеннән (хуҗалык әгъзалары са-

нын, махсуслаштырылуын һәм иң кулай үлчәмнәрен исәпкә алып) чыгып, крестьян-фермер хуҗалыгы алып бару өчен, шәхси ярдәмче хуҗалык, индивиуаль торак төзелеше, күмәк бакчачылык, яшелчәчелек, дача төзү өчен җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре әлеге Кодексның 127 статьясы нигезендә билгеләнә.

2. Законда тыелмаган башка максатлар өчен җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре эшчәнлекнең шушы төрләре өчен җирләр бүлеп бирүнең расланган нормалары буенча йә шәһәр төзелеше һәм проект-техник документлары нигезендә билгеләнә.

3. Хосусый милектә булырга мөмкин булган аерымланган су объектларының (ябык сулыкларның) иң чик күләмнәре Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

63 статья. Буш җир кишәрлекләрен төзелеш өчен бирү үзенчәлекләре

1. Җирләрдән файдалануны территориаль планлаштыру һәм территорияне үстерү ихтыяҗлары нигезендә вәкаләтле органнар дәүләт милкендәге һәм җирле үзидарә йә төзелеш подряды милкендәге буш җир кишәрлекләрен промышленность, транспорт максатлары һәм башка максатлар өчен бирү буенча үз инициативалары белән конкурслар һәм аукционнар игълан итәләр.

Мондый чакта җир кишәрлегенең нинди хокукта бирелүе турында хәбәр ителә.

2. Җир кишәрлекләрендә төзү хокукы алу өчен конкурслар һәм аукционнар законнарда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

64 статья. Дәүләт ихтыяҗларында һәм җирле үзидарә ихтыяҗларында төзелмәләрне сүтәргә һәм җир кишәрлекләрен кире алырга кирәк булган очракта төзелеш өчен җир кишәрлекләре бирү шартлары

1. Вәкаләтле органнар буш булмаган җир кишәрлекләрен төзелеш өчен бирү буенча конкурс яисә аукцион игълан итә алалар, әмма бу игълан итү, җир кишәрлекләре гражданнарның һәм юридик затларның нинди хокукында булуларына карамастан, җир кишәрлекләрен һәм башка күчемсез мөлкәтне читләштерү зонасы расланганнан, игълан ителгәннән һәм дәүләт җир кадастрында теркәлгәннән

һәм аларның кучемсез мөлкәтен сатып алганнан алданрак була алмый.

2. Җир кишәрлекләрен читләштеру зонасы аларны тартып алырга кимендә бер ел кала игълан итә, ул әлеге Кодексның 118 статьясында каралган нигезләрдә һәм тәртиптә башкарыла. Җир кишәрлеген бер елдан алдарак тартып алу аның биләучесе ризалыгы белән генә рөхсәт ителә.

65 статья. Җир кишәрлекләрен индивидуаль торак төзелеше өчен биру

Гражданнарның индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләре бирүне сорап язган гаризалары махсус исәпкә алына һәм, бүлеп биру өчен мәйданнар әзер булгач, канәгатьләндерелә.

Индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләре гражданнарга милеккә, гомерлек мирас итеп биләүгә яисә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелә.

66 статья. Җир кишәрлекләрен торак, бакчачылык, терлекчелек, яшелчәчелек, дача һәм гражданнарның коммерциячел булмаган гараж берләшмәләренә биру

1. Җир кишәрлекләре бирү турында гражданнардан гаризалар керү тәртибенә карап, бакчачылык, терлекчелек, яшелчәчелек өчен, индивидуаль торак, дача һәм гараж төзү өчен вәкаләтле органнар гражданнарның коммерциячел булмаган берләшмәләрен оештыру өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирүгә ярдәм итәләр.

2. Җир кишәрлеге башта гражданнарның коммерциячел булмаган берләшмәсенә вакытын чикләп файдалануга бүлеп бирелә, эчке планлаштыру һәм төзелеш проекты расланганнан һәм җир кишәрлеген натурага чыгарганнан яисә төзелеш тәмамланганнан соң гражданнарның коммерциячел булмаган берләшмәләре әгъзаларына милекчелек хокукында яисә башка хокукта конкрет җир кишәрлекләре рәсмиләштерелә.

Гомуми файдаланудагы җирләр (юллар, аркылы чыгу юллары, мәйданчыклар, саклanучы зоналар һәм башкалар) гражданнарның коммерциячел булмаган берләшмәләренә юридик зат буларак милек итеп яисә башка хокукта бирелә.

3. Җир кишәрлеге гражданнарның коммерциячел булмаган гараж яисә терлекчелек берләшмәсенә аның уставы нигезендә, аның әгъзаларының пайларын билгеләгән килеш, милек итеп бирелергә мөмкин.

4. Гражданнарның коммерциячел булмаган шушы берләшмәләренә җир кишәрлекләре бирү билгеләнгән тәртиптә аларны дәүләт теркәвенә алганнан һәм аларның әгъзаларының исемлеге раслангаbнан соң гамәлгә ашырыла.

5. Гражданнарның яңа төзелә торган коммерциячел булмаган бакчачылык һәм дача берләшмәләрен планлаштыруда шәһәр төзелешенең расланган документлары нигезендә аларны торак пунктлары категориясенә кертү мөмкинлеге дә күздә тотылырга тиеш.

<u>67 статья.</u> Җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыруның гомуми шартлары

1. Җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру - дәүләт милкендәге һәм җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә тапшыру ул.

2. Җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру гражданнарның һәм юридик затларның гаризалары буенча вәкаләтле органнар тарафыннан башкарыла.

3. Җир кишәрлекләрен гражданнар милкенә түләүсез тапшыру әлеге Кодекста билгеләнгән нормалар чикләрендә башкарыла.

Гомуми мәйданы милеккә түләүсез тапшырыла торган җир кишәрлеге мәйданы нормасыннан арткан җир кишәрлеге кадастр (норматив) бәясеннән дә түбән булмаган бәягә сатып алына йә тулы күләмдә даими (вакыты чикләнмичә) файдалануда, гражданның гомерлек мирас итеп биләвендә кала.

Күрсәтелгән җир кишәрлекләре булган гражданнарны аларны сатып алырга яисә арендага алырга мәҗбүр итү тыела.

4. Җир кишәрлеген хосусыйлаштыру мәҗбүри тәртиптә башкарыла алмый. Җир кишәрлекләрен хосусыйлаштырудан баш тарту, шәһәр төзелешенең һәм җир төзү эшләрен оештыруның расланган документларын исәпкә алып, законнарда каралган нигезләрдә генә рөхсәт ителә.

5. Корылмалары булган җир кишәрлекләрен милеккә тапшыру шәһәр төзелеше документлары нигезендә аларның планлаштырылучы

максатчыл билгеләнешен исәпкә алып башкарыла.

6. Җир кишәрлеге әлеге кишәрлектәге бина, төзелмә, корылма милекчесе (өлеш милекчеләре) тарафыннан гына хосусыйлаштырылырга мөмкин.

7. Территория чикләре, сервитутлар һәм йөкләтүләр турында тиешенчә рәсмиләштерелгән документлары булмаса, аларны билгеләгәнче һәм рәсмиләштергәнче җир кишәрлекләре хосусыйлаштырылырга тиеш түгел.

8. Төрле затларга караган берничә күчемсез мөлкәт объекты урнашкан җир кишәрлеге, әгәр барлык мөрәҗәгать итүчеләрнең җир кишәрлегенә гомуми милекчелек режимына буйсынулары турындагы йөкләмәләре шартнамәгә кертелсә генә, сатылырга яисә гомуми милекчелек хокукы белән милеккә тапшырылырга мөмкин.

9. Хосусыйлаштырылучы кишәрлекнең чикләре сервитутлар билгеләү зарурлыгын максималь бетерерлек итеп ачыкланырга тиеш.

10. Гомуми файдаланудагы елга һәм башка сулыклар ярларындагы, аларга керү юлларындагы җир кишәрлекләре файдалануга элек бирелгән булсалар да, яр буенча иркен барырлык, су транспорты килеп туктарлык, балык тоту һәм су коену мөмкинлекләре булырлык итеп кимендә 20 м киңлектә калдырганда гына, ә торак пунктларында шәһәр төзелеше документлары нигезендә генә милеккә тапшырылырга мөмкин.

11. Агач-куаклар үскән җир кишәрлеген хосусыйлаштыру аңа милекчелек хокукы барлыкка килүне аңлатмый. Алардан файдалану һәм кисү урман турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гражданнарның коммерциячел булмаган бакча һәм дача берләшмәләренең, авыл хуҗалыгы оешмаларының һәм башка мөрәҗәгать итүчеләрнең территорияләрендә урнашкан агач-куаклы җир кишәрлекләре аларны саклау һәм карау, урман турындагы законнарны үтәү шарты белән генә хосусыйлаштырылырга мөмкин.

12. Гражданның һәм юридик затның гомерлек мирас итеп биләү, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану яисә арендалау хокукында булган җир кишәрлеген хосусыйлаштыру турындагы мәсьәләне хәл итү өчен биләүче, файдаланучы яисә арендалаучы түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә тиеш:

а) әгәр кишәрлектә корылмалар төзелгән булса, җир кишәрлегендә урнашкан бинага, төзелмәгә, корылмага милек хокукын

бәхәссез раслаучы документлар;

б) җир кишәрлегенә хокукны раслаучы документлар, җир кишәрлеге сызымнары (планнары);

в) җир кишәрлегендә урнашкан барлык биналар, төзелмәләр, корылмалар милекчеләренең гаризалары.

Бакчачылык, яшелчәчелек, дача һәм гражданнарның башка коммерциячел булмаган берләшмәләре өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр таләп ителә:

гражданнарның коммерциячел булмаган берләшмәсе тарафыннан җир кишәрлеге хосусыйлаштырылу турында гомуми җыелыш карары;

җир кишәрлегенең планы;

үзләре милкенә кишәрлекләр тапшыру турында гражданнарның коммерциячел булмаган берләшмәләре әгъзаларының гаризалары.

**68 статья.** Хосусыйлаштырганда предприятиеләрнең җир кишәрлекләренә хокуклар алу үзенчәлекләре

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырылган предприятиеләр хосусыйлаштырылган көннән соң алты ай эчендә җир кишәрлегенә хокукларын яңадан рәсмиләштерергә тиеш.

Хосусыйлаштырылган предприятиеләр биләгән җир кишәрлекләре әлеге предприятиеләргә милеккә даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга яисә арендага бирелә.

2. Дәүләт предприятиеләрен акционер җәмгыятьләр итеп үзгәртү барышында, шулай ук хуҗалык җәмгыятьләре төзегәндә, шул исәптән чит ил инвестицияләре катнашында да, алар урнашкан җир кишәрлекләре, аларның хакы устав капиталына кертелеп, милек итеп тапшырылырга мөмкин.

Әгәр хосусыйлаштырылган предприятиедә үзе биләгән җир кишәрлегенә милекчелек хокукын алу зарурлыгы барлыкка килсә, җир аның устав капиталына кертем, пай, дәүләт өлеше сыйфатында милек итеп тапшырылырга, йә кадастр (норматив) хакыннан түбән булмаган бәягә сатылырга мөмкин.

3. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырылган предприятие били торган җир кишәрлеген хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру алымнары турындагы карарны Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең

әлеге предприятиене хосусыйлаштыруны хәл иткән орган кабул итә.

4. Җир кишәрлеген предприятие милкенә тапшыру (сату) тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

69 статья. Күп фатирлы торак йортларның йорт янындагы җир кишәрлекләре

1. Дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге (йә өлешчә хосусыйлаштырылган) күп фатирлы торак йортларның йорт янындагы җир кишәрлекләре дәүләт милке яисә җирле үзидарә милке булалар һәм күрсәтелгән йортлар белән идарә итүче оешмаларга вакыты чикләнмичә (даими) файдалануга биреләләр. 2. Күп фатирлы торак йортларның йорт янындагы җир кишәрлекләреннән файдалану законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

70 статья. Файдалы казылмалар яткан мәйданнардагы, электр үткәргеч линияләр турысындагы зоналарда һәм сәнәгать предприятиеләренең санитар-саклау зоналарында җир кишәрлекләре бирү

1. Файдалы казылмалар яткан мәйданнардагы җир кишәрлекләрен бирү бары тик җир асты байлыкларыннан файдаланучы ризалыгы һәм (яисә) файдалану хокукына лицензияләр бирергә вәкаләтле орган рөхсәте белән генә башкарыла.

2. Сәнәгать предприятиеләренең санитар-саклану зонасында, электр үткәргеч линияләр турысында җир кишәрлекләре бирү шәһәр төзелеше, экология һәм башка дәүләт нормаларын һәм стандартларын үтәгән килеш файдалану рөхсәт ителгәндә генә гамәлгә ашырыла.

Бу зоналарда торак төзелешенә, гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык берләшмәләренә яңа җир кишәрлекләре бирү рөхсәт ителми.

71 статья. Эзләнү эшләре алып барылганда җирләрдән файдалану

1. Геодезия, геофизика эшләрен, геологик рәсемгә төшерү, геологик разведка, эзләнү һәм башка төрле тикшеренүләр белән шөгыльләнүче оешмалар эзләнү эшләрен алып бару турында Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең тиешле органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карар һәм җир кишәрлегенең милекчесе, биләүчесе, аннан файдаланучы һәм аны арендалаучы белән төзелә торган шартнамә нигезендә, җир кишәрлегенең максатчыл билгеләнешенә бәйсез рәвештә, әлеге эшләрне барлык җирләрдә дә алып баралар. Җир кишәрлекләре тикшеренү эшләре алып бару өчен тартып алынмый.

2. Шартнамәдә эшләрне алып бару вакытлары һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен түләү күләмнәре, китерелгән зыянны кайтару һәм аларны максатчыл билгеләнешендә файдаланырлык хәлгә китерү вазыйфалары билгеләнә.

3. Килешүгә ирешелмәгән очракта, бәхәс суд тәртибендә карала.

4. Эзләнү эшләрен алып баручы оешмалар җир кишәрлекләрен максатчыл билгеләнешендә файдаланырлык хәлгә китергәннән соң, аларны акт буенча җир кишәрлекләренең милекчеләренә, аларны биләүчеләргә, алардан файдаланучыларга һәм аларны арендалаучыларга тапшыралар.

5. Җир кишәрлекләрен файдаланырлык хәлгә китерү – эшләр барышында, ә бу мөмкин булмаганда, шартнамәдә каралган вакытта башкарыла.

6. Эзләнү эшләре алып баручы оешмаларга эшләрне башкару технологиясе буенча, җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның җирләрдән файдалануларын тулысынча яисә өлешчә чикләп, вакытлы корылмалар өчен, җайланмаларны, техниканы урнаштыру, чимал складлары һәм башка корылмалар урнаштыру өчен җир кишәрлекләре таләп ителгәндә, алар җир салымы яисә аренда өчен түлиләр һәм җир кишәрлекләре милекчеләренә, аларны биләүчеләргә, алардан файдаланучыларга һәм аларны арендалаучыларга китерелгән зыянны тулысынча кайтаралар.

72 статья. Җир кишәрлекләренә билгеләнгән файдалану чорын узып алынган хокук

Гражданнарның һәм юридик затларның җир кишәрлекләренә билгеләнгән файдалану чоры узып хокук алулары законнар нигезендә башкарыла.

73 статья. Җир кишәрлеге чикләре

1. Җир кишәрлеге чикләрен урыннарда һәм хариталарда алдан билгеләү шушы кишәрлек өчен урын сайлаганда аны бирү турындагы карар кабул ителгәнче башкарыла.

2. Җир кишәрлекләрен бирү турында карар кабул ителгәннән соң, урыннарда аның чикләре билгеләнә.

3. Җир кишәрлеге чикләренең планнарын әзерләү, җир кишәрлеген тасвирлау, ызан араларына билгеләр кую тиешле рөхсәте (лицензиясе) булган затлар тарафыннан җир кишәрлеге алучы исәбеннән башкарыла.

4. Җир кишәрлекләре чикләренең планнары җир эшләрен оештыру эшендә саклана һәм җир кишәрлегенә хокукны таныклаучы документларны рәсмиләштергәндә кулланыла.

74 статья. Җир кишәрлекләренә хокукны таныклаучы документлар

Дәүләт милкендәге, җирле үзидарә милкендәге җирләрдән бирелүче җир кишәрлегенә хокукларны таныклаучы документлар түбәндәгеләр була: җир кишәрлегенә милекчелек, гомерлек мирас итеп биләү, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукына дәүләт акты (таныклыгы), аренда шартнамәсе яисә җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе.

Бу документларда җир кишәрлегенә бирелә торган хокук, сервитутлар, йөкләтүләр, максатчыл билгеләнеш, рөхсәт ителгән файдалану, җир кишәрлеген үзләштерү чорлары күрсәтелә.

Әлеге дәүләт актларының (таныклыкларның) һәм якынча шартнамәләрнең рәвешләре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

<u>75 статья.</u> Җир кишәрлегенә хокукның барлыкка килү мизгеле

Гражданнарның һәм юридик затларның җир кишәрлекләренә милекчелек хокукы һәм җир кишәрлекләрендәге башка хокуклар җир кишәрлегенә хокукны дәүләт теркәвенә алган мизгелдән барлыкка киләләр.

<u>76 статья.</u> Җир кишәрлекләренә хокукны махсус теркәүгә һәм
дәүләт теркәвенә алуның мәҗбүрилеге

1. Җир кишәрлекләренә милекчелек хокукы һәм башка хокуклар, әлеге хокукларны чикләү, аларның килеп чыгуы, күчүе һәм туктатылуы махсус теркәүгә һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

Махсус теркәү Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы буенча дәүләт комитеты һәм аның урыннардагы органнары тарафыннан башкарыла.

Дәүләт теркәве Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Кишәрлек алганда җир кишәрлегенә яңа барлыкка килгән хокуклар да һәм җир кишәрлекләре, күчемсез мөлкәт белән алыш-биреш итүләр нәтиҗәсендә алынган хокуклар да дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

3. Дәүләт теркәве тәртибе "Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны теркәү турында"гы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

4. Дәүләт теркәлмәгән җир хокукларын яклауны һәм кагылгысызлыкны гарантияләми.

12 бүлек. Җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның, аларны арендалаучыларның хокуклары һәм вазыйфалары

<u>77 статья.</u> Җир кишәрлекләре милекчеләренең хокуклары

Җир кишәрлекләре милекчесе үзе теләгәнчә теләсә нинди ысуллар белән һәм, җир кишәрлекләрен биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү әлеге Кодекста ни дәрәҗәдә рөхсәт ителгән булса шул дәрәҗәдә аларны били, алардан файдалана һәм алар

белән эш итә, шул исәптән ул түбәндәгеләргә дә хокуклы:

а) рөхсәт ителгән файдалану нигезендә җир кишәрлегендә мөстәкыйль хуҗалык итәргә;

б) җир кишәрлегендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, торфтан, эчәргә яраклы җир асты суларыннан, шулай ук күпьеллык үсентеләрдән һәм су объектларыннан хуҗалык ихтыяҗлары өчен законнар нигезендә файдаланырга;

в) җир кишәрлекләренең максатчыл билгеләнеше нигезендә, шәһәр төзелеше һәм проектлау документлары нигезендә торак биналары, җитештерү, мәдәни-көнкүреш һәм башка төр биналар, төзелмәләр, корылмалар салырга, аларны үзгәртеп корырга һәм сүтәргә;

г) экология, төзелеш, санитария-гигиена һәм башка төрле махсус таләпләр (нормалар, кагыйдәләр, нормативлар) нигезендә, дәүләтнең тиешле органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килештереп, сугару, киптерү, культура-техник һәм башка мелиорация эшләре алып барырга, буалар буарга, бүтән сусаклагычлар ясарга;

д) авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренә һәм үсентеләренә, алардан алынган уңышка һәм аларны сатудан килгән табышка милекчелек хокукына, җир кишәрлеген арендага тапшыру очраклары моңа керми;

е) җир кишәрлеге закон нигезендә гражданлык әйләнешеннән алынмаган булса яисә гражданлык әйләнешендә чикләнелмәгән булса, кир кишәрлеге белән ирекле эш итәргә;

ж) җир кишәрлегеннән ихтыяри рәвештә баш тартырга;

з) җир кишәрлеге алынганда, сатылу бәясен алырга;

и) законнарда тыелмаган башка гамәлләрне кылырга.

<u>78 статья.</u> Җир кишәрлекләрен биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның хокуклары

1. Җир кишәрлекләрен биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар җир кишәрлекләре милекчеләренең әлеге Кодексның 77 статьясындагы "а","б","в","г","д","ж" пунктчаларында билгеләнгән барлык хокукларына да ия булалар, шулай ук граждан законнарында яисә милекче белән төзелгән шартнамәдә

билгеләнгән чикләрдә кишәрлекне биләү һәм аннан файдалану буенча үз хокукларын гамәлгә ашыралар.

2. Әгәр җир кишәрлегә милекчесе белән төзелгән шартнамәдә башкача каралмаган булса, җир кишәрлекләрен биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның әлеге кишәрлек белән эш итәргә хокуклары юк.

3. Җир кишәрлекләрен биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар, әлеге статьяның 1 пунктында билгеләнгән хокуклар белән беррәттән, җир кишәрлекләрен төзекләндерү һәм яхшыртуга киткән чыгымнар өчен компенсация алырга, җир кишәрлекләре дәүләт ихтыяҗлары өчен алынганда, алынмый калган файданы да кертеп, зыянны түләттерергә хокуклы.

<u>79 статья.</u> Җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның вазыйфалары

1. Җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

а) җир кишәрлегеннән аның максатчыл билгеләнеше буенча, шулай ук, табигать объекты һәм табигый байлык буларак, җиргә зыян китерми торган ысуллар белән файдаланырга;

б) җир кишәрлекләренең башка милекчеләренең, аларны биләүчеләренең, алардан файдаланучыларының һәм аларны арендалаучыларының хокукларын бозмаска;

в) туфракның уңдырышлылыгын арттырырга, җирләрне саклау гамәлләрен тормышка ашырырга, урманнардан, елга-сулардан һәм башка табигать объектларыннан файдалану тәртибен үтәргә, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерүгә юл куймаска;

г) җирләрдән файдалануның билгеләнгән режимын үтәргә;

д) җир кишәрлекләрен үзләштерү чоры җир турындагы законнарда яисә шартнамәдә турыдан-туры каралганда, җир кишәрлекләреннән файдалануга үз вакытында керешергә;

е) җир кишәрлекләре өчен түләүләрне вакытында башкарырга;

ж) төзелешне, төзекләндерүне һәм күчемсез мөлкәт тотуны шәһәр төзелешенең һәм архитектура төзелешенең расланган документлары, гамәлдәге төзелеш, экология, санитария-гигиена, ян-

гынга каршы һәм башка төрле таләпләр (нормалар, кагыйдәләр, нормативлар) нигезендә, тиешле дәүләт органнары белән килештереп башкарырга;

з) җирләрнең торышы һәм алардан файдалану буенча җир турындагы законнарда билгеләнгән мәгълүматларны җирле администрациягә яисә җирле үзидарә органнарына вакытында тапшырырга;

и) Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары карарлары нигезендә уздырылучы төрле эзләнү эшләре өчен шартнамә шартларында җир кишәрлекләре бирергә;

к) җирләрдән файдалану һәм аларны саклау буенча дәүләт тикшерүе органнары урындагы затларының үз компетенцияләре чикләрендә бирелгән күрсәтмәләрен үтәргә;

л) җир кишәрлегендәге ызан билгеләрен, геодезик һәм башка мәгълүмати тамгаларны урнаштырырга һәм сакларга;

м) җир кишәрлеге планнарын һәм җир кишәрлегенә хокук турындагы башка документларны сакларга һәм хокук дәвамчысына тапшырырга.

2. Җир кишәрлекләрен биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар җир кишәрлекләреннән яисә аларның өлешләреннән теге яки бу сәбәпләр аркасында файдалану мөмкин булмаган очракларда, алардан файдаланмый торган чор хакында җир милекчесенә хәбәр итәргә тиеш. Җир милекчесе бу очракта әлеге җир кишәрлекләрен яисә аларның өлешләрен шартнамәдә күрсәтелгән чорга башка затка тапшырырга хокуклы.

80 статья. Бина, төзелмә һәм корылма җимерелгәндә җир кишәрлегенә булган хокукның сакланып калуы

1. Бина, төзелмә, корылма җимерелгәндә, төзелеш өчен бирелгән җир кишәрлегенә хокук бинаны, төзелмәне, корылманы өч ел эчендә билгеләнгән тәртиптә торгыза башлау шарты белән сакланып кала.

Бу чор узганнан соң җир кишәрлегенә милекчелек хокукы яисә башка хокук әлеге Кодексның 115,116 статьяларында каралган нигезләрдә һәм тәртиптә туктатыла.

Җирле администрация яисә җирле үзидарә органы бу чорны озайтырга хокуклы, бәхәсле очракта бу чор суд тәртибендә озайтылырга мөмкин.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән очракларда җир кишәрлеген арендалау хокукын саклап калу шартлары аренда шартнамәсендә билгеләнә, әгәр алар шартнамәдә каралмаган булса, әлеге статьяның беренче пункты кагыйдәләре гамәлдә була.

81 статья. Җир кишәрлегенә хокукларны гамәлгә ашыру

1. Әгәр җир турындагы законнарда башкача билгеләнмәгән булса, гражданнар һәм юридик затлар җир кишәрлекләренә карата булган хокукларын үзләре теләгәнчә гамәлгә ашыралар.

2. Зат җир кишәрлегенә карата булган үз хокукларын гамәлгә ашырудан баш тарта ала, әмма мондый баш тарту башка затларның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылмаска һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китермәскә тиеш.

## 13 бүлек. Җир кишәрлекләре әйләнеше

82 статья. Җир кишәрлекләре әйләнеше төшенчәсе

1. Җир кишәрлекләре әйләнеше - Россия Федерациянең Граждан кодексы һәм әлеге Кодекста билгеләнгән үзенчәлекләр нигезендә, шартнамәләр төзеп һәм башка алыш-бирешләр ясап, җир кишәрлекләренең бер заттан икенче затка күчүе ул.

2. Әлеге Кодексның 83 статьясы нигезендә хосусый милеккә тапшырыла алмый торган җир кишәрлекләре әйләнештә була алмыйлар.

3. Авыл хуҗалыгы җитештерүе һәм крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләренең әйләнеше чикләнгән була һәм әйләнешләре әлеге Кодекс белән рөхсәт ителгән дәрәҗәдә генә бер заттан икенче затка күчәргә мөмкин.

83 статья. Хосусый милеккә тапшырылмый торган җирләр

Түбәндәгеләрнең җир кишәрлекләрен хосусый милеккә тапшыру тыела:

а) мәдәни һәм тарихи мирас объектларының;

б) дәүләт табигать тыюлыкларының, милли паркларның, табигать паркларының, дәүләт табигать заказникларының, табигать

ядкярләренең, дендрологик парклларның һәм ботан бакчаларының, дәвалау-савыктыру һәм курорт урыннарының, яшел зоналарның;

в) урман фондының;

г) су фондының;

д) гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (мәйданнар, урманнар, юллар, яр буйлары, парклар, урман парклары, скверлар, бакчалар, бульварлар, кызыну урыннары һәм гомуми файдаланудагы башка территорияләр);

е) гомуми файдаланудагы объектларның, инженерлык һәм табигатьне саклау элементларын урнаштыру өчен шәһәр төзелеше документларында каралган торак пунктларындагы һәм шәһәр яны зоналарының;

ж) билгеләнгән тәртиптә өйрәнелгән һәм расланган һәм аларны ачык юл белән чыгару каралган файдалы казылмалар чыганаклары яткан мәйданнарның;

з) предприятиеләрнең радиоактив, химик, биоген зарарлануга дучар булган зоналарының һәм санитар-саклау зоналарының;

и) дәүләт авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү һәм мәгариф учреждениеләренең тәҗрибә кырларының, нәсел, элита-орлыкчылык хуҗалыкларының, ат заводларының, балык питомникларының;

к) агроландшафт җир эшләре системаларының;

л) авыл көтүлекләренең, терлекләрне куып йөртү урыннарының, гомуми кулланылыштагы юллар, коелар, чишмәләр, эчәр су урыннарының һәм гражданнар җыены хәл итү буенча башка җир кишәрлекләре;

м) эчке су юллары яр буе полосаларының, гомуми файдаланудагы автомобиль һәм тимер юлларының, торбаүткәргеч һәм башка транспорт өчен бирелгән полосаларның, электрүткәргеч линияләрнең, елга портларының һәм вокзалларының, аэродромнарның һәм аэропортларның, һава юллары хәрәкәтен һәм суднолар йөрешен навигацион тәэмин итү корылмаларының, шулай ук күрсәтелгән транспорт төрләрен киңәйтү өчен резервланган җир кишәрлекләре;

н) торак пунктларыннан читкә чыгару яисә экологик һәм социаль нигезләр буенча күчерү планлаштырылган производстволарның;

о) бәхәсле территорияләрнең (бәхәсләр хәл ителгәнче).

Җир кишәрлегендәге биналарның, төзелмәләрнең һәм корылмаларның шул җир кишәрлегенә караган булу-булмаулары турында суд

бәхәсе очракларына да бу тыю кагыла;

п) законнар нигезендә хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектларның.

84 статья. Җир кишәрлекләрен хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав, туплау капиталына яисә җитештерү кооперативына пай кертеме сыйфатында тапшыру

Милекче яисә арендалаучы (милекче ризалыгы белән) җир кишәрлеген яисә аренда хокукын хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятләренең устав, туплау капиталы кертеме яисә җитештерү кооперативларының пай кертеме сыйфатында тапшырырга хокуклы. Кертем күләме яклар килешүе буенча билгеләнә, кирәк булганда бәйсез эксперт бәяләмәсе белән раслана. Бу чакта җир кишәрлегенә милек яисә субаренда хокукы дәүләт теркәве узганнан соң юридик затка күчә.

85 статья. Җир кишәрлекләрен сату-алу

1. Хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яисә аларның өлешләрен сату-алу максатчыл билгеләнешләрен үзгәртмичә, алардагы күчемсез мөлкәт белән бергә яисә аннан башка гына законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Уртак милектәге җир кишәрлеген яисә аның бер өлешен сату барлык милекчеләр ризалыгы белән законнар нигезендә тормышка ашырыла.

86 статья. Күчемсез мөлкәт белән алыш-биреш иткәндә җир кишәрлегенә хокук алу

1. Җир кишәрлеге милекчесенә караган һәм шул җир кишәрлегендә урнашкан бинага, төзелмәгә яисә корылмага булган милекчелек хокукы бинаны, төзелмәне, (корылманы) алучыга күчкәндә җир кишәрлегенә хокук та күчә, ул яклар килешүендә билгеләнә.

Әгәр бинаны, төзелмәне һәм корылманы аерып алу турында шартнамәдә башкасы каралмаса, бина, корылма, төзелмә белән җир кишәрлегенең шул һәм аннан файдалану өчен кирәк булган җир кишәрлегенең шул

өлешенә милек хокукы да сатып алучыга күчә.

2. Әгәр законда башкасы каралмаган булса, биләүдә, файдалануда булган җир кишәрлегендә урнашкан бинага, төзелмәгә, корылмага милекчелек хокукы яисә башка хокук сатып алучыга күчкәндә, сатып алучыга җир кишәрлегенә хокук та элекке биләүчесендә, файдаланучысында булган шартларда, күләмдә һәм шул ук рөхсәт ителгән файдалану өчен күчә.

87 статья. Җир кишәрлекләрен залогка тапшыру

1. Үз милкендә җир кишәрлекләре булган затлар аларны залогка тапшырырга хокуклы.

2. Җир кишәрлекләрен залогка тапшыру тәртибе һәм шартлары ипотека турындагы законнар белән билгеләнә.

88 статья. Җир кишәрлекләрен алмашу

1. Дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмичә) файдалану яисә гомерлек мирас итеп биләү яисә арендалау хокукында файдаланучы зат, җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмичә) файдалану, гомерлек мирас итеп биләү яисә арендалау хокукында файдаланучы башка затның җир кишәрлеге белән әлеге җир кишәрлеген бирүче вәкаләтле орган ризалыгы нигезендә алмаштырырга хокуклы.

2. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмичә) файдалану, гомерлек мирас итеп биләү яисә арендалау хокукында файдаланган зат вәкаләтле орган ризалыгы белән, бу хокукларны алмаштырып, алыш-биреш итү ясалган гражданга яисә юридик затка карый торган башка җир кишәрлеге милке хокукын алырга хокуклы.

89 статья. Җир кишәрлекләрен бүләк итеп бирү

1. Җир кишәрлеге милекчесе бүләк итеп бирү шартнамәсе буенча җир кишәрлеген яисә аның бер өлешен башка гражданга, юридик затка, шулай ук Татарстан Республикасына яисә җирле үзидарәгә тапшырырга хокуклы.

2. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары уртак милектә булган җир кишәрлегенең

бер өлешен Татарстан Республикасына яисә җирле үзидарәгә бүләк итеп бирү тәртибендә күчүче җир кишәрлегеннән баш тартмаска тиеш, моңа гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге өчен, тереклек һәм үсемлек дөньясы әчен куркыныч янаучы, җир кишәрлеге хакыннан артып китә торган бурыч йөкләүләре булгандагы очраклар керми.

90 статья. Җир кишәрлекләрен мирас итеп алу

1. Граждан вафат булган очракта, аңа караган җир кишәрлегенә яки кишәрлек өлешенә милек хокукы яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукы мирас булып васыять буенча яки граждан законнары нигезендә закон буенча башка затларга күчә.

2. Варислар арасында җир кишәрлеген максатчыл билгеләнешләре һәм рөхсәт ителгән файдаланылышы буенча җир кишәрлекләренә билгеләнгән минималь нормаларны бозуга китерерлек итеп бүленеш рәхсәт ителми.

91 статья. Җир кишәрлекләрен арендалау үзенчәлекләре

1. Гомуми милектәге җир кишәрлекләре аның барлык милекчеләре ризалыгы белән генә арендага бирелә ала.

2. Әгәр законда яисә аренда шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, төзелеш өчен бирелгән җир кишәрлеген арендага бирү хокукы арендачы тарафыннан бу кишәрлектәге төзелеш йөкләмәсе белән бергә алынырга, шулай ук аренда вакыты чикләрендә бары тик милекчесе ризалыгы белән генә залогка тапшырылырга мөмкин.

3. Милекче үзенең җир кишәрлеген сатканда, бу җир кишәрлеген арендалаучы аны сатып алуда өстенлекле хокукка ия.

Милекченең җир кишәрлеген сатуы аренда шартнамәсенең гамәлдә булуын өзми.

4. Әгәр аренда шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, җир кишәрлеген арендалаучы граждан вафат булган яисә юридик зат үзгәртеп корылган очракта, аларның аренда шартнамәсе буенча хокуклары һәм бурычлары граждан законнары нигезендә вариска яки хокук дәвамчысына күчә.

5. Җир кишәрлегенең бер өлешен арендага биргән очракта

аның чикләре тиешле тәртиптә билгеләнергә тиеш.

6. Дәүләт милкендәге җирләрдән һәм җирле үзидарә милкендәге җирләрдән коммерция максатында файдалану өчен җир кишәрлеге бирү бинаны, корылманы, төзелмәне дәүләт милкенә, җирле үзидарә милкенә, җир кишәрлеген коммерция максатында файдалануның килешү вакыты тәмамлангач, милекче ризалыгы белән, аренда шартнамәсе белән түләүсез бирү йөкләмәсе каралырга мөмкин.

92 статья. Җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләрне рәсмиләштерү

1. Җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләрне алыш биреш итүче зат яки затлар йә алар вәкаләт биргән башка затлар имза салган һәм аларның эчтәлеген чагылдыручы документларны гражданлык законнары таләпләре нигезендә язма рәвештә башкарыла.

2. Биналары, корылмалары һәм төзелмәләре булган җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләр, алардагы биналарның, корылмаларның һәм төзелмәләрнең җир кишәрлекләренә карата нинди хокукта булуларына карамастан, бер генә шартнамә белән рәсмиләштерелә.

3. Шартнамәдә түбәндәге шартлар күрсәтелергә тиеш:

а) алыш-биреш итүче яклар;

б) алыш-биреш итүнең төре;

в) алыш-биреш итүнең предметы (җир кишәрлегенең тасвирламасы, йөкләү һәм сервитутларын да кертеп, аның хокукый режимы, теркәү номеры, җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт турындагы белешмәләр);

г) сатып алучының җир кишәрлегенә, анда урнашкан башка күчемсез мөлкәткә хокукларны алу нигезләре (сатып алу, мирас итеп алу һәм законнар нигезендә башка сәбәпләр);

д) әлеге җир кишәрлегенә һәм аңа нык бәйле башка күчемсез мөлкәткә карата алыш-биреш итүне тыю булмауны күрсәтү;

е) җир кишәрлегенә өченче зат хокуклары белән бәйләнешле йөкләүләрнең (залогка салу, арендага бирү, махсус режим белән файдалану, сервитутлар, өстенлекле хокуклар һәм законнар нигезендә башка йөкләүләр) булу-булмавын күрсәтү;

ж) җир кишәрлегенә хокукны тапшыру вакыты;

з) алыш-биреш итүнең бәясе;

и) якларның бурычлары.

93 статья. Җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләрнең гамәлгә яраксыз булуы

1. Җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләр граждан законнарында каралган нигезләрдә суд карары белән гамәлгә яраксыз дип табылырга мөмкин.

2. Әгәр җир кишәрлеге белән алыш-биреш итү гамәлгә яраксыз дип табылган өлешеннән башка да башкарыла алса, алыш-биреш итүнең бер өлешен гамәлгә яраксыз дип табу аны тулаем яраксызга чыгармый.

3. Җир кишәрлекләре белән алыш-биреш итүләрнең гамәлгә яраксызлыгы нәтиҗәләре граждан законнары белән билгеләнә.

14 бүлек. Авыл хуҗалыгы җирләренең әйләнеше

94 статья. Гражданнарга һәм юридик затларга авыл хуҗалыгы җирләрен биргәндәге таләпләр

1. Крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен авыл хуҗалыгы җирләре һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүгә бәйле башка төрле индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеге өчен авыл хуҗалыгы җирләре 18 яшькә җиткән, авыл хуҗалыгы белгечлеге яки авыл хуҗалыгында эш тәҗрибәсе булган, имтиханнар тапшырган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүен алып баруга лицензияләр алган гражданнарга бирелә.

Белгечлек таләпләре, имтихан бирү һәм лицензияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге статьяда күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүче хезмәткәрләре булган очракта, юридик затлар авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен авыл хуҗалыгы җирләре алырга мөмкин.

3. Авыл хуҗалыгы максатындагы җир кишәрлекләре әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүче гражданнар һәм юридик затлар милкендә, гомерлек мирас итеп биләүдә, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануда, аренда да булырга мөмкин.

4. Әлеге таләпләр шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, терлекчелек һәм яшелчәчелек, печән чабу һәм мал-туар көтү эшләрен алып бару өчен җир кишәрлекләрен алырга теләгән гражданнарга кагылмый.

95 статья. Авыл хуҗалыгы оешмалары җирләре

1. Җир кишәрлекләре авыл хуҗалыгы оешмаларына (хуҗалык ширкәтләренә һәм җәмгыятьләренә, җитештерү кооперативларына һәм башка коммерция оешмаларына) әлеге Кодекс нигезендә милеккә, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга яисә арендага түләүле һәм түләүсез бирелә ала.

2. Җир кишәрлеге авыл хуҗалыгы оешмасы милкенә бирелгән очракта, аның әгъзалары (катнашучылары) җиргә аерым әгъзага туры килгән җир кишәрлеге өлешенең кыйммәтен чагылдыручы пай хокукына ия булалар.

Җир пае әлеге Кодекс һәм авыл хуҗалыгы оешмалары уставлары нигезендә әйләнештә катнаша.

96 статья. Дәүләт авыл хуҗалыгы оешмалары җирләре

1. Җир кишәрлекләре дәүләт авыл хуҗалыгы оешмаларына даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга бирелә. 2. Дәүләт авыл хуҗалыгы оешмалары җир кишәрлекләрен законнар һәм үз уставлары нигезендә файдаланалар.

3. Җир пае әлеге Кодекс һәм авыл хуҗалыгы оешмаларының уставлары нигезендә әйләнештә катнаша.

97 статья. Авыл хуҗалыгы оешмаларында җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрен үзгәртеп кору

1. Авыл хуҗалыгы оешмаларын үзгәртеп корганда җир кишәрлекләре даими (вакыты чикләнмичә) файдалануда, арендада кала яисә авыл хуҗалыгы оешмаларында катнашучыларга, законнар нигезендә җир өлешенә хокуклы башка гражданнарга милеккә бирелә.

2. Хезмәт коллективы гомуми җыелышының хуҗалык җирен хосусыйлаштыру турындагы карары, район буенча милеккә бушлай тапшырыла торган уртача нормадан һәм җир өлеше алу хокукына ия

булган гражданнар саныннан чыгып, милеккә тапшырылучы җир микъдарын билгеләү өчен нигез була.

Хуҗалыкта җирләр җитмәгәндә, шулай ук җирләрне яңадан бүлү фонды булмаганда, җир өлеше күләме хуҗалыктагы авыл хуҗалыгы җирләреннән чыгып билгеләнә.

Колхозларда һәм башка авыл хуҗалыгы оешмаларында милеккә бушлай тапшырылучы җирнең уртача нормасы халык депутатларының җирле Советлары тарафыннан билгеләнә.

Җир өлешенә хокукка түбәндәгеләр ия:

а) үзгәртеп корыла торган хуҗалыкларның хезмәткәрләре;

б) мондый хуҗалыкларның территорияләрендә яшәүче шушы хуҗалыкларның пенсионерлары;

в) үзгәртеп корыла торган хуҗалыкларның вакытлы рәвештә читтә булган хезмәткәрләре (вакытлы хезмәттәге хәрби хезмәткәрләр, хуҗалык стипендиатлары һәм элекке эш урынына кире кайту хокукы булган башка затлар);

г) авылдагы социаль өлкәдә шөгыльләнүче затлар (бу хуҗалыклар территориясендә урнашкан мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, көнкүреш, элемтә, сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмалары хезмәткәрләре), әлеге җирлектә яшәүче көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсе пенсионерлары.

Хуҗалыкара әһәмияте булган социаль өлкә оешмаларында (участок сырхауханәләрендә, мәгариф учреждениеләрендә һәм башкаларда) эшләүче затларга җир өлешенә хокук үзләре хезмәт күрсәтүче зонага керүче хуҗалыкларның теләсә кайсыннан бирелергә мөмкин.

3. Җир өлешенә милек хокукы алган затлар түбәндәге хокукларга ия:

а) уртак авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен үз җир өлешләрен берләштерергә, төзелә торган ширкәтләргә, җәмгыятьләргә, җитештерү кооперативына гамәлгә кую кертеме сыйфатында кертергә;

б) үзенең җир өлешен мөлкәт паена алмаштырырга;

в) җир өлешен мирас итеп тапшырырга;

г) җир өлешен крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару яки шәхси ярдәмче хуҗалык итеп файдаланыла торган җир кишәрлеген билгеләнгән нормага җиткерү өчен арттыру максатында натуралата алырга яисә аренда, рента йә гомерлек карап тоту шартнамәсе

шартларында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен оешмаларга һәм гражданнарга бирергә;

д) җир өлешен Татарстан Республикасына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, җир өлешләренең башка милекчеләренә, үзләре оештырган һәм авыл хуҗалыгы эшчәнлеге белән шөгыльләнүче предприятиеләргә сатарга;

е) авыл хуҗалыгы оешмасының үз милке хокукында булган җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алганда җир өлешенең хакын алырга.

4. Хуҗалык ширкәтенә, җәмгыятенә, җитештерү кооперативына, крестьян (фермер) хуҗалыгына өлеш фонды исәбеннән тапшырылган җирләр аларның милке хокукында була.

Хуҗалык ширкәтләренә һәм җәмгыятьләренә, җитештерү кооперативларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, файдалану чикләре билгеләнгән авыл хуҗалыгы җирләренә һәм бүтән җирләргә карата, планда һәм урында чикләре аерып алынган башкалар файдалануындагы җирләрдән кала, шулай ук урман фонды җирләреннән кала, милек хокукы турында документ бирелә.

5. Авыл хуҗалыгы җирләренең милеккә бушлай тапшырылганнан соң калган өлеше, планда (кирәк булганда урында) чикләре билгеләнеп, җирләрне яңадан бүлү буенча дәүләт фондына кертелә. Бу чакта яңа оешкан хуҗалыклар бу җирләрне арендага алуда яисә даими (вакыты чикләнмичә) файдалануда, әгәр алар җитештерү куәтен саклау өчен кирәк булса, өстенлекле хокукка ия булалар.

6. Ярдәмче авыл хуҗалыгы сәнәгать предприятиесенең бер өлеше буларак хосусыйлаштырылырга мөмкин. Бу вакытта предприятиегә ярдәмче хуҗалык алып бару өчен беркетелгән җир кишәрлекләре ярдәмче хуҗалыкка җирдән файдалануның максатчыл билгеләнешен үзгәртмичә арендага бирелә.

Юридик зат статусына ия булган ярдәмче авыл хуҗалыгы предприятиеләре җирләрне әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда хосусыйлаштыралар.

<u>98 статья.</u> Җир өлешенә милекчелек хокукын раслаучы документлар

Җир өлешенә милекчелек хокукы булган затларга билгеләнгән үрнәктәге таныклык бирелә.

99 статья. Крестьян (фермер) хуҗалыклары җирләре

1. Крестьян (фермер) хуҗалыгына җир кишәрлекләре милеккә, гомерлек мирас итеп биләүгә , даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга яки арендага бирелергә мөмкин.

2. Крестьян (фермер) хуҗалыгы, милеккә бушлай тапшырыла торган уртача билгеләнгән нормалардан тыш, өстәмә рәвештә үз милкенә җир кишәрлекләре алырга яки даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, гомерлек мирас итеп биләүгә әлеге Кодекста билгеләнгән иң чик күләмнәрдә алырга мөмкин. Арендага бирелә торган җирләрнең мәйданы чикләнми.

3. Крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару өчен җир кишәрлекләре алган һәм авыл җирендә торак йорты булган гражданнарның йорт янындагы җир кишәрлеге саклана, ул крестьян (фермер) хуҗалыгы файдалана торган җирләр составына кертелми.

100 статья. Авыл хуҗалыгы оешмалары әгъзалары булган гражданнарга крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү тәртибе

1. Крестьян (фермер) хуҗалагын алып бару өчен авыл хуҗалыгы оешмаларыннан чыкканда, оешмада катнашучы гомуми җыелышка йә ул вәкаләт биргән органга җир кишәрлеге бүлеп бирү турында үтенеч белән, аның үлчәме һәм крестьян (фермер) хуҗалыгын оештырырга теләге булган гаилә әгъзаларының саны, үзләре теләгән урыны күрсәтелгән гариза бирә.

2. Авыл хуҗалыгы оешмасында катнашучыларның гомуми җыелышы йә ул вәкаләт биргән орган оешма әгъзасы гариза биргән көннән алып бер ай вакыт эчендә җир бүлеп бирү турында карар кабул итә һәм тиешле документны гариза бирүчегә тапшыра. Натуралата бүлеп бирелә торган җир кишәрлегенең үлчәмнәре һәм урыны турында гомуми җыелыш карары җир кишәрлеге бүлеп бирү турында җирле администрация тарафыннан карар чыгару өчен нигез була.

Документлар кергән көннән башлап ике ай вакыт эчендә җир ресурслары һәм җир реформасы буенча район комитеты җир кишәрлегенең чикләрен билгели, крестьян (фермер) хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы оешмасы башлыгына җир кишәрлегенә милекне гомерлек мирас итеп биләү хокукына яисә аннан даими (вакыты чикләнмичә)

файдалану турында дәүләт актын (таныклыгын) бирә.

Җир кишәрлеген бүлеп бирүдән баш тартуга карата судка шикаять бирелергә мөмкин.

3. Крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару өчен бирелә торган җир кишәрлекләре туфракның уңдырышлылыгы ягыннан әлеге хуҗалык буенча кадастр бәяләмәсенең уртача дәрәҗәсенә туры килергә тиеш.

4. Җир өлешенең үлчәме милеккә бушлай бирелә торган җирнең район буенча уртача нормасыннан ким булган очракта, крестьян (фермер) хуҗалыгының авыл хуҗалыгы оешмасыннан чыгучы әгъзалары җирле администрациягә, милеккә бушлай бирелә торган җирнең район буенча уртача нормасына җиткереп, запас җирләрнең махсус фондыннан үзләренә милеккә бушлай өстәмә җир кишәрлекләре сорап язган гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

<u>101 статья.</u> Авыл хуҗалыгы оешмалары әгъзалары булып тормаган гражданнарга крестьян (фермер) хуҗалыкларын алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү тәртибе

1. Авыл хуҗалыгы оешмалары әгъзалары булып тормаган гражданнарга крестьян (фермер) хуҗалыклары алып бару өчен җир кишәрлекләре аларның гаризалары нигезендә запас җирләрнең махсус фондыннан бирелә.

2. Җирле администрациягә бирелгән гаризада сорап язылган җир кишәрлегеннән файдалану максаты, аның күздә тотылган үлчәмнәре һәм урыны, крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары составы, ә арендага алган очракта, аннан файдалану вакыты да күрсәтелә.

3. Җир кишәрлеген бирү яки бирүдән баш тарту турында карар гариза бирелгән көннән алып бер ай вакыт эчендә җирле администрация тарафыннан кабул ителә.

4. Җир кишәрлеген бирүдән баш тартуга карата судка шикаять бирелергә мөмкин.

102 статья. Крестьян (фермер) хуҗалыгының җир кишәрлеген мирас итү

1. Крестьян (фермер) хуҗалыгында милек хокукындагы җир кишәрлеген мирас итү граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2. Крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзасы булмып тормаган варис хуҗалыкның башка әгъзалары ризалыгы белән крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару хокукына яисә ул мирастан үзенә тиешле җир кишәрлеге әлеше хакы күләмендә крестьян (фермер) хуҗалыгыннан компенсация алу хокукына ия була. Компенсация түләү тәртибе законнар белән билгеләнә.

Крестьян (фермер) хуҗалыгының соңгы әгъзасы вафат булган очракта, варислар крестьян (фермер) хуҗалыгын алып баруны дәвам итәргә, крестьян (фермер) хуҗалыгын хуҗалык җәмгыяте (ширкәте) яисә җитештерү кооперативы итеп үзгәртергә, җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы оешмаларына яисә башка крестьян (фермер) хуҗалыкларына арендага бирергә хокуклы.

Әгәр варисларның берсе дә крестьян (фермер) хуҗалыгын алып барырга теләмәсә, алар крестьян (фермер) хуҗалыгына карый торган җир кишәрлеген бер ел дәвамында аерып бирергә тиешләр.

3. Балигъ булмаган граждан җир кишәрлегенең варисы булганда, аның законлы вәкилләре бу җир кишәрлеген варис балигъ булу яшенә җиткәнче арендага биреп тора алалар.

4. Җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләүче әлеге җир кишәрлегеннән файдалану һәм аны биләү хокукын нәсел буенча крестьян (фермер) хуҗалыгының башка әгъзаларына, ә алар булмаганда башка гражданнарга тапшырырга хокуклы. Җир кишәрлеген биләү яки аннан файдалану хокукы, крестьян (фермер) хуҗалыгын алып баруны дәвам иттерү шарты белән варисларга күчә.

5. Варислар булмаган очракта яисә җир кишәрлегенә мирастан баш тартканда, җир кишәрлеге җирләрне бүлү буенча дәүләт фондына күчерелә.

103 статья. Крестьян (фермер) хуҗалыгының күчемсез мөлкәтенә милекчелек хокукы күчкәндә җир кишәрлегенә хокукның күчүе

1. Крестьян (фермер) хуҗалыгының бинага, төзелмәгә, корылмага һәм башка күчемсез мөлкәтенә милек хокукы сату яки бүләк итеп бирү тәртибендә яңа милекчегә күчкәндә, крестьян (фермер) хуҗалыгын алып баруны дәвам иттерү шарты белән, җир кишәрлегенә булган тиешле хокуклар да күчә.

2. Мөлкәтнең яңа милекчесе җир кишәрлегенә хокукын законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерергә тиеш.

104 статья. Авыл хуҗалыгы җирләрен сатып алуга өстенлекле хокук

Крестьян (фермер) хуҗалыгына яисә авыл хуҗалыгы оешмасына караган авыл хуҗалыгы максатындагы җир кишәрлеген сатканда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан вәкаләтле дәүләт органы, җирле үзидарәнең тиешле органы, катнаш территорияләрдә урнашкан авыл хуҗалыгы оешмалары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары бу җир кишәрлеген сатып алу буенча өстенлекле хокукка ия була, ул гомуми милек хокукында өлешләп сатып алу буенча өстенлекле хокукка карата граждан законнарында билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

105 статья. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләре

1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлегенә йорт яны җир кишәрлеге һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен билгеләнгән җир кишәрлеге (басу кишәрлеге) керә.

2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару әчен җир кишәрлекләре милеккә, гомерлек мирас итеп биләүгә яки даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга әлеге Кодекста билгеләнгән нормалар чикләрендә бирелә.

3. Йорт яны җир кишәрлегендә торак йортлар һәм башка төзелмәләр салына. Басу кишәрлегендә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү эше алып барыла һәм кирәкле хуҗалык корылмалары, шу-

лай ук торак йортлар төзелергә мөмкин.

106 статья. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, дача һәм терлекчелек берләшмәләре өчен җир кишәрлекләре

1. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык һәм дача берләшмәләренә җир кишәрлекләре җиләк-җимеш, яшелчә үстерү, ял итү, торак һәм хуҗалык төзелмәләре һәм корылмалары төзү өчен бирелә.

2. Гражданнарның коммерциягә карамаган терлекчелек ширкәтләренә җир кишәрлекләре терлек үрчетү белән бергә азык әзерләү максатларында хуҗалык корылмалары төзү өчен бирелә.

3. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, дача һәм терлекчелек берләшмәләрендә җир кишәрлекләреннән файдалану тәртибе әлеге Кодекс, законнар һәм башка норматив-хокукый актлар һәм гражданнарның коммерциягә карамаган әлеге берләшмәләренең уставлары белән билгеләнә.

4. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык һәм терлекчелек берләшмәләре әгъзаларының җир кишәрлекләре һәм аларда төзелгән күчемсез мөлкәт гражданнарның коммерциягә карамаган берләшмәләренең гомуми мөлкәтендә мондый берләшмә әгъзасына тигән өлеше (пае) белән бергә әйләнештә була.

5. Бакча кишәрлекләрен мөстәкыйль җир кишәрлекләренә бүлү күмәк бакчачылык максатлары өчен законнарда билгеләнгән минималь мәйдан нормалары кысаларында башкарылырга мөмкин.

107 статья. Яшелчәчелек, печән чабу, терлек-туар көтү өчен җир кишәрлекләре

1. Яшелчәчелек, печән чабу һәм терлек-туар көтү өчен, җир кишәрлекләре арендага яисә шартнамә буенча вакытын чикләп файдалануга бирелә.

2. Яшелчәчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләре яшелчә, бәрәңге, бакча һәм җиләк культуралары үстерү өчен файдаланыла. Аларда күпьеллык җимеш агачлары утырту рәхсәт ителми.

3. Кирәк булганда, яшелчәчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә, җирле шартларны исәпкә алып, ял итү, эш кораллары

саклау һәм җил-яңгырдан саклану өчен индивидуаль һәм гомуми файдаланылыштагы вакытлыча төзелмәләр һәм корылмалар төзелергә мөмкин.

4. Яшелчәчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләренең арендалау, вакытын чикләп файдалану хокукы беткәндә, анда вакытлыча төзелгән корылмалар һәм төзелмәләр бу корылмаларның һәм төзелмәләрнең хуҗалары тарафыннан сүтелергә йә, биналарның, корылмаларның хакы түләнмичә, алар исәбеннән сүтелергә тиеш.

5. Җирле үзидарә файдалануына печән чабу һәм терлек-туар көтү өчен тапшырылган җир кишәрлекләре, урман фонды җирләрендәге җир кишәрлекләрен дә кертеп, мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

<u>108 статья.</u> Хезмәт урыныннан бирелә торган имана җирләре

1. Транспорт, урман хуҗалыгы, урман промышленносте, су, балыкчылык, аучылык хуҗалыкларының һәм башка тармакларның оешмалары үз хезмәткәрләренә үзләре файдалануында булган җирләрдән вакытын чикләп файдалану хокукында авыл хуҗалыгы эшләрендә файдалану өчен имана җирләре бирәләр.

2. Хезмәт урыныннан бирелә торган имана җирләренә хокуклар түбәндәгеләргә саклана:

а) картлык яки инвалидлык буенча пенсиягә китү сәбәпле, хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылган хезмәткәрләргә;

б) вакытлы хәрби гамәли хезмәткә алынган яки һөнәри белем бирүнең мәгариф учреждениеләренә укырга кергән хезмәткәрләрнең гаиләләренә (хезмәт итү яки уку елларының барлык вакытында);

в) хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган хезмәткәрләрнең гаиләләренә: хезмәткә яраксыз ире йә хатыны яки ата-анасы өчен - гомер буена, ә балалары өчен - алар балигъ булганчы.

3. Оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрен туктаткан хезмәткәр үзенә бирелгән имана җирен уңыш җыеп алу өчен кирәк булган вакытка кадәр файдаланырга хокуклы.

109 статья. Авыл хуҗалыгы оешмаларының җирләрен үзгәрткәндә, аларны кабат бүлү

Хуҗалык ширкәтләре һәм оешмалары, җитештерү кооперативлары һәм авыл хуҗалыгының башка оешмалары җирләрне бүлешү яки бүлеп бирү юлы белән кабат үзгәрткәндә, җирләр, алардан файдалануны рациональ оештыру таләпләрен һәм барлык якларның мәнфәгатьләрен исәпкә алып, аларның әгъзаларына тиешле өлешләрне һәм пайларны исәптә тотып, оешманың гомуми җыелышы карары буенча һәм уставы нигезендә бүленәләр.

## 15 бүлек. Җир кишәрлекләрен тартып алганда авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтуларны һәм зыяннарны түләтү

110 статья. Җир кишәрлекләрен тартып алганда авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүе югалтулары

1. Авыл хуҗалыгын һәм урман хуҗалыгын алып баруга бәйләнеше булмаган максатларда файдалану өчен авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрен, урман фонды җирләрен тартып алганда, авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтулар җир кишәрлекләрен бирү турында карар кабул ителгәннән соң өч ай вакыт эчендә әлеге җир кишәрлеге бирелә торган зат тарафыннан түләнергә тиеш.

2. Дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлекләре даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга яки милеккә бушлай бирелгәндә авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтулар түләтелә. Җир кишәрлекләрен максатчыл билгеләнешен үзгәртеп саткан яисә арендага биргән очракта, авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтулар җир кишәрлеге бәясенә кертелә һәм аренда түләвен билгеләгәндә исәпкә алына.

3. Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтуларны исәпләгәндә тартып алынучы җир кишәрлекләрендә җыелганнан да ким булмаган күләмдә авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы продукциясен җитештерү максатында, яңа җирләрне үзләштерү хакының һәм гамәлдәге җирләрне яхшырту хакының нормативлары

кулланыла.

4. Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтуларны түләтү тәртибе һәм күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

111 статья. Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтуларны түләтү тәртибендә керүче акчаларны файдалану

Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы җитештерүендәге югалтуларны түләтүдән керүче акчалар Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм мондый җирләр урнашкан җирле бюджетларга күчерелә һәм законнар нигезендә файдаланыла.

112 статья. Җирләрне тартып алудан килгән зыян

Җир кишәрлекләрен тартып алудан килгән зыян җир кишәрлекләренең шул зыянны күргән милекчеләренә, аларны биләүчеләргә, алардан файдаланучыларга һәм арендалаучыларга тулы күләмдә (алынмый калган файданы да кертеп) түләнергә тиеш.

Зыяннар өчен түләүне шул җир кишәрлекләре бирелгән затлар башкара.

16 бүлек. Җир кишәрлекләренә хокукларны туктату һәм чикләү

113 статья. Гражданнарның һәм юридик затларның җир кишәрлекләренә хокукларын туктату нигезләре

1. Җир кишәрлекләренә милек, гомерлек мирас итеп биләү хокукы, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану, вакыты чикләнеп файдалану, арендалау хокукы түбәндәге нигезләрдә туктатыла:

1) җир кишәрлегеннән ихтыярый баш тарту;

2) җир белән әлеге Кодекс нигезендә башкарылган алыш-биреш итүләр нәтиҗәсендә үз җир кишәрлеген аерып алу;

3) җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алу (сатып алу);

4) җир кишәрлеген реквизицияләү яисә конфискацияләү;

5) законнарны бозып файдаланылган җир кишәрлеген мәҗбүри тартып алу;

6) юридик затны бетерү (үзгәртеп кору) яисә гражданның үлеме;

7) җир кишәрлеге өчен аның милекчесе йөкләмәләре буенча җәза бирелү;

8) корылма, бина, төзелмә хокукларының башка затка күчүе.

2. Җир кишәрлеген арендалау яисә вакытын чикләп файдалану хокукы әлеге статьяның беренче пунктында күрсәтелгән нигезләрдә, шулай ук аренда яисә вакытын чикләп файдалану шартнамәсендә билгеләнгән нигезләрдә туктатыла.

3. Хезмәт урыныннан бирелә торган имана җиренә хокук хезмәт мөнәсәбәтләре өзелүгә бәйле рәвештә туктатыла.

4. Җир кишәрлегеннән чикләүле файдалану хокукы (сервитут) сервитут билгеләнгән нигезләр бетү сәбәпле яисә сервитутлар йөкләнгән җир кишәрлеге үз максатында файланыла алмаган очракларда туктатылырга мөмкин.

<u>114 статья.</u> Җир кишәрлекләреннән баш тарту

Җир кишәрлеге милекчесе, аны биләүче яки аннан файдаланучы кишәрлеккә карата үз хокукларыннан баш тартуы турында язмача белдергән очракта, бу җир кишәрлеге, урнашуына карап, дәүләт җирләре яки җирле үзидарә җирләре составына кертелә.

Җир кишәрлегенә хокукны туктату җир кишәрлеген биргән вәкаләтле органның җир кишәрлегенә хокукларны туктату турындагы карары нигезендә башкарыла, ә милек хокукы граждан законнарында каралган тәртиптә туктатыла.

<u>115 статья.</u> Җир кишәрлекләренә хокукларны мәҗбүри туктату нигезләре

Җир кишәрлекләренә хокукларны мәҗбүри туктату түбәндәге очракларда башкарылырга мөмкин:

а) җир кишәрлегеннән максатчыл яисә рөхсәт ителгәнчә файдаланмаганда;

б) түбәндәге хокук бозулар җирләрдән файдалану һәм аларны саклауны тикшереп торучы дәүләт органнарының күрсәтмәләрендә

билгеләнгән вакытта бетерелмәгәндә:

- җирләрне химик һәм радиоактив матдәләр, җитештерү калдыклары, агып төшүче сулар белән пычрату, бактерия-паразит һәм карантин тудыручы организмнар белән зарарлау;
- вакытлыча биләнүче җирләрне кайтарып бирү вакытын үтәмәү;
- туфракның уңдырышлы катламын бозу һәм юкка чыгару;
- чүп үләннәре үрчетү;
- туфракны җил һәм су эрозиясеннән саклау, туфрак торышын бозучы башка тискәре процессларны булдырмау өчен мәҗбүри гамәлләрне үтәмәү;
- җирләрдән табигый ресурсларны, археология объектларын һәм тарихи-мәдәни мирас объектларын бозуга һәм юкка чыгаруга китерә торган алымнар белән файдалану;
- табигатьне саклау, табигый тыюлык, савыктыру, рекреацион максатлардагы җирләрдән, махсус файдалану шартлары булган башка җирләрдән билгеләнгән режимны бозып файдалану;
- җирләрне чүп-чарлау;

в) авыл хуҗалыгы максатындагы җир кишәрлегеннән өч ел буена файдаланмау, җир кишәрлеген үзләштерү, мелиоратив төзелеш, табигый бәла-казалардан соң торгызылу вакыты һәм шулай ук файдалану мөмкинлеген юкка чыгаручы башка шартлар исәпкә алынмый;

г) төзелеш өчен бирелгән җир кишәрлеге өч ел дәвамында файдаланылмаса, әгәр шартнамәдә төзелеп бетүнең башка озаграк чоры күрсәтелмәгән булса;

д) җир кишәрлеген реквизицияләү;

е) җир кишәрлеген конфискацияләү;

ж) җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алу;

з) закон буенча җир кишәрлеге тиешле затныкы булмаганда аны аерып алу;

и) милекченең җир кишәрлеге буенча йөкләмәләрен үтәмәгән өчен җәза бирелү.

116 статья. Законнарны бозып файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокукларны туктату тәртибе

1. Җир кишәрлеген милеккә, гомерлек мирас итеп биләүгә

алу, аннан даими (вакыты чикләнмичә) файдалану, вакыты чикләнеп файдалану һәм аны арендалау хокукларын әлеге Кодексның 115 статьясындагы "а", "б","в", "г" пунктларында каралган нигезләрдә туктату түбәндәге тәртиптә башкарыла:

а) югарыда күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган очракта, гаепле юридик затлар яки гражданнар җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт контролендә тотучы махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан административ хокук бозулар турындагы законнар нигезендә җаваплылыкка тартылалар;

б) административ җаваплылыкка тартылу белән беррәттән, әлеге статьяның "а" пунктында күрсәтелгән органнар хокук бозуларны өч айга кадәр бетерү турында кисәтү ясыйлар.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән хокук бозулар бетерелмәгәндә, аларны ачыклаган органнар җир кишәрлеген биргән вәкаләтле органга әлеге җир кишәрлегенә хокукларның туктатылуы турында тәкъдим кертәләр.

Җир кишәрлегенә хокукларның бетерелүе гаепле затларны китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

3. Әлеге статьяда каралган очракларда җир кишәрлекләренә хокукларны туктату вәкаләтле орган карарына таянып законнар нигезендә башкарыла.

Карарның күчермәсе җир кишәрлеге милекчесенә, биләүчесенә, аннан файдаланучыга, аны арендалаучыга кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә тапшырыла һәм җир кишәрлегенә хокукларны теркәүче дәүләт органына җибәрелә.

4. Җир кишәрлегенә хокукларны туктату турындагы карар белән җир кишәрлеге милекчесе, аны биләүче, аннан файдаланучы, аны арендалаучы риза булмаган очракта, алар бу карарның күчермәсен алганнан соң унбиш көн эчендә карарны кабул иткән органга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бу очракта карар үтәлми һәм җир кишәрлегенә хокукларны мәҗбүри туктату турындагы таләп судка җибәрелә.

5. Җир кишәрлегенә милек хокукын туктату түләп алу тәртибендә башкарыла, моңа әлеге Кодексның 115 статьясындагы "б","в","г" пунктлары керми.

207



117 статья. Кайбер категориядәге җирләрне тартып алу үзенчәлекләре

Уртача район дәрәҗәсен үтеп киткән кадастр бәясе белән урман фонды һәм авыл хуҗалыгы җирләреннән авыл хуҗалыгына һәм урман хуҗалыгына карамаган максатларда җирләр тартып алу башка вариантлар булмаганда гына һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүгә бәйле, сәламәтлек саклау объектлары, магистраль труба үткәргечләр, элемтә линияләре, электр тапшыру линияләре һәм башка корылмалар төзүгә бәйле аерым очракларда гына рөхсәт ителә.

Аеруча уңдырышлы җирләрне, фәнни-тикшерену һәм мәгариф учреждениеләренең тәҗрибә басуларын авыл хуҗалыгы ихтыяҗларына бәйле булмаган максатлар өчен, махсус сакланылучы табигать һәм тарихи-мәдәни объектлар биләп торган җирләрне аларның эшчәнлегенә бәйле булмаган максатлар өчен тартып алу рөхсәт ителми. Андый җирләрнең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

118 статья. Дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен тартып алу (түләп алу)

1. Билгеләнгән тәртиптә расланган шәһәр төзелеше һәм җир эшләрен алып бару документлары дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен гражданнарның һәм юридик затларның милкендәге, гомерлек мирас итеп биләвендәге, даими (чикләнмәгән вакытка) файдаланудагы җир кишәрлекләрен тартып алу турында карар кабул итү әчен нигез булып тора.

Башка очракларда җир кишәрлекләрен милекчеләреннән, биләүчеләреннән, файдаланучыларыннан дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗларына дигән булып мәҗбүри тартып алуга юл куелмый.

2. Федераль, республика һәм җирле программаларны, проектларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен тартып алу дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен тартып алу, дип санала.

3. Җир кишәрлеген дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алу (түләп алу) турында карар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителә.

Җир кишәрлеген дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары әчен тартып алу турында карарны әзерләү һәм кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган нигезләмә белән билгеләнә.

4. Җир кишәрлеген дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен милекчеләрдән тартып алу түләп алу тәртибендә башкарыла.

Җир кишәрлеге кем ихтыяҗларында тартып алынудан чыгып, түләү Татарстан Республикасы, тиешле район, шәһәр яисә җирле үзидарә тарафыннан башкарыла.

Җир кишәрлеген дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗларында милекчеләрдән тартып алу өчен түләү (түләү хакы), түләүнең вакыты һәм башка шартлар кишәрлек милекчесе килешүе белән билгеләнә. Килешү тартып алына торган кишәрлекнең сатып алу бәясен Татарстан Республикасы, район, шәһәр яисә җирле үзидарәнең түләү йөкләмәсен үз эченә ала.

Җир кишәрлеге милекчесе түләп алу буенча тәкъдим ителгән шартлар белән килешмәгән очракта, аның урынына башка җир кишәрлеген бирү мөмкинлеген дә кертеп, җир кишәрлеген түләп алу турында карар кабул иткән орган түләп алу турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5. Әгәр җир кишәрлеге милекчесе, аны биләүче, аннан файдаланучы калган өлешне элекке максатында файдалана алмаса яисә ул минималь нормадан түбәнрәк булса, җир кишәрлеге тулысынча тартып алына (түләп алына).

6. Җир кишәрлекләренең һәм башка күчемсез мөлкәтнең салым салу максатларында билгеләнгән тәртиптә расланган бәяләү материаллары, шулай ук җир кишәрлеген яки башка күчемсез мөлкәтне сату-алу буенча кылынган соңгы килешү бәясе дәүләт ихтыяҗларында теләсә кайсы затның җир хокукларын туктаткан өчен компенсация күләмен билгеләү өчен нигез була.

<u>119 статья.</u> Җир кишәрлекләрен реквизицияләү һәм конфискацияләү

1. Табигый бәла-казалар, һәлакәтләр, эпидемияләр, эпизоотияләр һәм гадәттән тыш башка хәлләр булганда, җир кишәрлеге яки аның бер өлеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары

өчен законда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда реквизицияләнергә мөмкин, бу очракта милекчегә шушы кишәрлекнең хакы кайтарыла һәм тартып алуга бәйле башка чыгымнар да түләнә (реквизиция).

2. Җир кишәрлеге яки аның бер өлеше реквизицияләнгән зат, реквизиция үткәрүгә сәбәп булган хәлләр тукталгач, сакланып калган җир кишәрлеген яисә аның өлешен кире кайтаруны суд аша таләп итәргә хаклы.

3. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән хәлләр барлыкка килгәндә һәм җир кишәрлеген яки аның бер өлешен реквизицияләү зарур булмаганда, алар бу хәлләр барышында дәүләт һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен вакытлыча файдаланылырга мөмкин, бу очракта милекченең хокукларын вакытлыча чикләүгә бәйле зыян түләнә.

Җир кишәрлеген милекчегә кайтарып бирү мөмкинлеге булмаган очракта законнар нигезендә аның бәясе, шулай ук төзелмәләр, корылмалар һәм башка күчемсез мөлкәт бәясе түләнә.

Җир кишәрлеге милекчесенә, аны биләүчегә, аннан файдаланучыга зыянны түләү өчен бирелә торган компенсация бәясенә карата судка яки арбитраж судка дәгъва белдерелергә мөмкин.

Карантин һәм хуҗалык эшчәнлеген билгеле бер вакытта туктатып тору игълан ителгән очракта җир кишәрлекләре реквизицияләнми, ә аларның милекчеләренә, аларны биләүчеләргә, алардан файдаланучыларга, аларны арендалаучыларга моңа бәйле рәвештә китерелгән зыян түләнә.

4. Җинаять кылган һәм башка хокук бозулар өчен законда каралган очракларда җир кишәрлеге яки аның бер өлеше суд карары белән милекчесеннән түләүсез тартып алынырга (конфискацияләнергә) мөмкин.

5. Җир кишәрлеген яки аның өлешен милекчедән административ тәртиптә конфискацияләү рөхсәт ителми.

<u>120 статья.</u> Дәүләт ихтыяҗлары килеп туган очракларда җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның хокукларын чикләү

Дәүләт ихтыяҗлары килеп туган очракларда җир кишәрлекләре

милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның хокукларын чикләү территориаль зоналаштыру турында, ачык сервитутларны билгеләү турында карарлар кабул итү юлы белән һәм законда каралган башка очракларда билгеләнә.

121 статья. Шәһәр яны зоналарында һәм авылларның резерв җирләрендә җирләрдән файдаланудагы чикләүләр

1. Торак пунктларының, җирләрне зоналаштыруның генераль планнары нигезендә торак пунктларының резерв җирләрендә һәм шәһәр яны зоналарында хосусый милеккә җир кишәрлекләре бирү тыелырга мөмкин.

2. Шәһәр яны зонасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм табигый ресурсларны куллану кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янарлык һәм табигать объектларына яисә әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерерлек булса, алардан файдалану чикләнә яисә тыела.

3. Шәһәрләрнең һәм шәһәр яны зоналарының резерв җирләрендә җир кишәрлекләреннән файдалануны чикләүләрнең конкрет исемлеге әлеге Кодексның 22 статьясында билгеләнгән тәртиптә, башка торак пунктларның резерв территорияләрендә - җирле администрация, җирле үзидарә органы тарафыннан раслана.

4. Резерв территориядәге җир кишәрлекләре гражданнарга һәм юридик затларга арендага бирелергә мөмкин.

122 статья. Дәүләт ихтыяҗлары әчен җир кишәрлекләрен тартып алганда милекчеләрнең, биләүчеләрнең һәм файдаланучыларның хокуклары гарантияләре яисә аларның хокукларын чикләү

1. Дәүләт ихтыяҗлары өчен гражданнардан җир кишәрлекләрен тартып алу (түләп алу) түбәндәгеләрдән соң гамәлгә ашырыла:

а) үз теләкләре буенча аларга җир кишәрлеге бәясенә аның хакын һәм андагы торак, җитештерү һәм башка биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне исәпкә алып, җирле администрация тарафыннан башка җир кишәрлеге бүлеп бирелгәннән соң яисә, яклар килешүендә башкасы каралмаган булса, уңайлыклары булган торак

биргәннән соң;

б) җир кишәрлеген тартып алуга бәйле яисә җир кишәрлегенә хокукларны чикләүгә бәйле башка барлык зыяннарны тулы күләмдә кайтарганнан соң.

2. Җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары өчен оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан юридик затлардан тартып алу (түләп алу) түбәндәге шартларда башкарылырга мөмкин:

а) тартып алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан торак, җитештерү биналары, башка биналар, корылмалар һәм төзелмәләр, мелиоратив, балык үрчетү хуҗалыгы объектларын һәм башка объектларны түләп алу яисә башка җир кишәрлегендә яңа объектлар төзү;

б) законнар нигезендә башка барлык зыяннарны тулы күләмдә кайтару.

3. Җир кишәрлекләренең милекчеләре, биләүчеләре, файдаланучылары, арендалаучылары җир кишәрлеге тартып алынырга (түләп алынырга) бер елдан да соңга калмыйча, тартып алу (түләп алу) хакында карар кабул иткән орган тарафыннан язмача хәбәр алырга тиеш. Хәбәр алган көннән соң бер ел вакыт эчендә җир кишәрлеген тартып алу (түләп алу) бары тик аның милекчесе, биләүчесе, файдаланучысы һәм арендалаучысы ризалыгы белән генә рөхсәт ителә.

4. Бүлеп бирелүче җир кишәрлегенең һәм тартып алына торганы урынына яңа урында төзелә торган бинаның, төзелмәнең, корылманың хакы тартып алынган мөлкәтнең хакыннан артып китә алмый.

## 17 бүлек. Җир турындагы бәхәсләр

### 123 статья. Җиргә бәйле хокукларны яклау

Җир кишәрлекләренә гражданнарның һәм юридик затларның хокукларын яклау законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 124 статья. Җир турындагы бәхәсләрне хәл итү

1. Җиргә булган хокукларны гамәлгә ашыру һәм җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салу, аларның законнар нигезендә

кем карамагында булуларыннан чыгып, суд яисә арбитраж суд тарафыннан карала.

2. Суд яисә арбитраж суд эшне карый башлаганчы, җир турындагы бәхәс якларның берәрсе тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органына яисә җирле үзидарә органына йә якларның килешүе буенча өченчел судка хәл ителү өчен тапшырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органы яисә җирле үзидарә органы кабул иткән карарга карата судка, арбитраж судка шикаять бирелергә мөмкин.

## 18 бүлек. Җир турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

__125 статья.__ Җир турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

Җир турындагы законнарны бозган гражданнар, юридик һәм урындагы затлар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

__126 статья.__ Җир турындагы законнарны бозып китерелгән зыянны түләтү

Юридик затлар һәм гражданнар, җир турындагы законнарны бозу нәтиҗәсендә үзләре китергән зыянны граждан законнары нигезендә түләргә тиешләр.

## 19 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

__127 статья.__ Гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик үлчәмнәре

Гражданнарга гаилә исәбеннән милеккә, гомерлек мирас итеп биләүгә һәм файдалануга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик үлчәмнәрен түбәндәге исәпләрдә билгеләргә:

а) крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен - 100 гектарга кадәр;

б) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

– җир әлешен алуга милек хокукына ия булган гражданнарга – шул җир өлеше үлчәменә кадәр, авыл җирендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып барырга теләүче башка гражданнарга – 0,15 тән 1 гектарга кадәр; шул исәптән авыл торак пунктлары сызыгы чикләрендә – 0,5 гектарга кадәр;

в) шәхси торак төзелеше өчен:

– республика буйсынуындагы шәһәрләрдә, шулай ук аларның шәһәр яны зоналарында урнашкан шәхси торак төзелеше кишәрлекләрендә – 0,04 тән 0,15 гектарга кадәр;

– район буйсынуындагы шәһәрләрдә һәм башка шәһәр торак пунктларында – 0,12 дән 0,25 гектарга кадәр;

г) бакчачылык һәм дача төзелеше өчен – 0,04тән 0,15 гектарга кадәр.

Гражданнарга яшелчәчелек өчен вакытын чикләп файдалануга бирелә торган җир кишәрлекләре үлчәмнәре 0,15 гектарга кадәр билгеләнә, ә күп балалы гаиләләр (5 кешедән артыграк) өчен – гаиләнең һәр әгъзасына өстәмә рәвештә 0,02 гектар билгеләнә.

<u>128 статья.</u> Авыл хуҗалыгы җирләренең норматив бәясе

Авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләренең мәйдан берәмлегенә карата рубльләр белән норматив бәясе сөрүлекләр һәм күпьеллык утыртмалар өчен – бөртекле культураларның гадәти уңышын, печәнлекләр, көтүлекләр өчен – терлек азыгы берәмлекләренең аларга карата гамәлдәге сатып алу бәяләре белән капитализацияләү чорының исәп-хисап вакыты эчендә аларны җитештерүгә киткән иҗтимагый зарури чыгымнар аермасының тапкырчыгышына тигез зурлык буларак билгеләнә;

– җир өлешен йә крестьян (фермер) хуҗалыгындагы авыл хуҗалыгы җир кишәрлеген мирас итеп алганда норматив бәя алардан файдалану өчен һәр елда алына торган җир салымы күләмен 200 мәртәбә арттырып билгеләнә.

<u>129 статья.</u> Әлеге Кодексны гамәлгә кертү

1. Татарстан Республикасының Җир кодексын матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге Кодексны кабул итүгә бәйле рәвештә түбәндәгеләр

214



үз көчен югалткан дип танырга:

- 1991 елның 19 апрелендә кабул ителгән Татарстан Республикасының Җир кодексы;

- "Татарстан Республикасының Җир кодексын гамәлгә кертү турында" Татарстан Республикасы Югары Советының 1991 елның 19 апрелендәге карары;

- "Җир реформасы турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1991 елның 19 апрелендәге карарының 3 пункты;

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1994 елның 21 июлендәге "Татарстан Республикасында 1994 ел өчен җир салымын исәпләп чыгару тәртибе турында, җирнең норматив бәясен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 4 мартындагы "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында"гы карарын үзгәртү турында"гы карарының 3 пунктындагы икенче абзацы.

3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

а) "Җир өчен түләү турында"гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында", "Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында"гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында", "Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары турында"гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында", "Җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында", "Татарстан Республикасының Урман кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектларын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә;

б) үзенең норматив-хокукый актларын Татарстан Республикасының Җир кодексына яраклаштырырга тиеш;

в) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары тарафыннан Татарстан Республикасының Җир кодексына каршы килә торган үзләренең норматив-хокукый актларын яңадан карауларын һәм юкка чыгаруларын тәэмин итәргә;

г) 1999 елның 1 гыйнварена кадәр:

- авыл хуҗалыгы җирләрен сату-алу, аларны залогка салу, җирләрне бәяләү мәсьәләләрен җайга салучы закон проектларын,

әлеге Кодексны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка законнарның проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә;

- Татарстан Республикасында җир базарын үстерү мәсьәләләрен җайга сала торган кирәкле норматив-хокукый актлар кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 10 июле
N 1736